Шикаятьләрдән һәм аларга кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүчеләр яши торган күпфатирлы йортның ишегалдындагы юлның һәм тротуарларның асфальт түшәмәсе 1983 елдан, йорт кулланылышка тапшырылганнан бирле ремонтланмаган һәм хәзерге вакытта бик нык таушалган хәлдә. Ишегалды территориясе, машина үтә торган юл өлеше һәм тротуарларның асфальт түшәмәсен ремонтлауны сорап, алар Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясенә, Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә, «“Уютный дом” идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә мөрәҗәгать иткән. Ләкин ишегалдындагы юл һәм тротуарларның асфальт түшәмәсен ремонтлау эшләре башкарылмаган. Юлларның шундый хәлдә булуы, алар санавынча, аларның иминлегенә һәм сәламәтлегенә яный.

Мөрәҗәгать итүчеләр фикеренчә, Тәртипнең 3.3 пункты, юл фондының бюджет ассигнованиеләрен бүлү вәкаләтен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына тапшырып, андый бүленешне башкарганда җирле администрация таянырга тиешле критерийлар билгеләми, бу әлеге фондтагы акчаларның ирекле бүленешенә һәм ремонтланырга тиешле юлларны һәм квартал эчендәге машина юлларын объектив булмаган сайлауга китерә.

Алар шулай ук Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренең 54 пунктындагы 1 пунктчасы юл территорияләрен карап тоту юлларны, тротуарларны, ясалма юл корылмаларын, квар-

тал эчендәге машина юлларын ремонтлауны үз эченә ала дип билгеләп, андый ремонт башкару тәртибен җайга салмый дип уйлыйлар. Моннан тыш, мөрәҗәгать итүчеләр билгеләгәнчә, Регламентның 2.1 һәм 2.2 бүлекчәләрендәге нигезләмәләр Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы юлларын җәйге һәм кышкы җыештыруның төп технологик операцияләре исемлегенә юллар, тротуарлар һәм квартал эчендәге машина юлларын ремонтлауны кертмиләр.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар Л.И. Новоселова, П.П. Гуров һәм Т.А. Миронова Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Казан шәһәренең муниципаль юл фонды турында» Казан шәһәр Думасының 2013 елның 29 ноябрендәге 2-27 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибенең 3.3 пунктын; Казан шәһәр Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренең 54 пунктындагы 1 пунктчасын; «Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын карап тоту тәртибе турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 13 августындагы 4735 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын һәм төзекләндерү элементларын карап тоту буенча эшләр башкару регламентының 2.1 һәм 2.2 бүлекчәләрендәге аерым нигезләмәләрне Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче өлеш) һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорыйлар, алар нигезендә закон һәм суд каршында һәркем тигез; Татарстан Республикасында кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгара яисә киметә торган законнар чыгарылмаска тиеш.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы тугызынчы өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды фәкать хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен башкарганда башка судлар яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән органнары компетенциясенә кергән барлык очракларда факттагы хәлләрне ачыклаудан һәм тикшерүдән тыелып кала.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану практикасындагы мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, «Казан шәһәренең муниципаль юл фонды турында» Казан шәһәр Думасының 2013 елның 29 ноябрендәге 2-27 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибенең 3.3 пункты ул юл фондының бюджет ассигнованиеләрен бүлү вәкаләтен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына тапшырып, андый бүленешне башкарганда җирле администрация таянырга тиешле критерийлар билгеләми торган дәрәҗәдә; Казан шәһәр Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренең 54 пунктындагы 1 пунктчасы ул юл территорияләрен карап тоту юлларны, тротуарларны, ясалма юл корылмаларын, квартал эчендәге машина юлларын ремонтлауны үз эченә ала дип билгеләп, андый ремонт башкару тәртибен җайга салмый торган дәрәҗәдә; «Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын карап тоту тәртибе турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 13 августындагы 4735 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын һәм төзекләндерү элементларын карап тоту буенча эшләр башкару регламентының 2.1 һәм 2.2 бүлекчәләрендәге аерым нигезләмәләр алар Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы юлларын җәйге һәм кышкы җыештыруның төп технологик операцияләренә юллар һәм тротуарлар ремонтлауны кертми торган дәрәҗәдә әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып торалар.

2. Мәрәҗәгать итүчеләр тарафыннан дәгъвалана торган хокукый нигезләмәләр юл эшчәнлеге, юлларны, шул исәптән тротуарларны, квартал эчендәге машина юлларын карап тоту һәм ремонтлау мәсьәләләренә, шулай ук җирле үзидарә органнарының муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләрен бүлү буенча вәкаләтләренә кагылалар.

Татарстан Республикасы Конституциясенең 10, 116 (беренче өлеш) һәм 118 (беренче өлеш) статьяларындагы үзара бәйле нигезләмәләр буенча Татарстан Республикасында җирле үзидарә таныла һәм гарантияләнә, ул үз вәкаләтләре чикләрендә мөстәкыйль һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне халыкның хәл итүен тәэмин итә, җирле үзидарә органнары муниципаль милеккә мөстәкыйль идарә итәләр, җирле бюджетны төзиләр, раслыйлар һәм үтиләр. Тиңдәш нигезләмәләр Россия Федерациясе Конституциясенең 12, 130 (1 өлеш) һәм 132 статьяларында беркетелгән.

Күрсәтелгән хокукый җайга салуга 1985 елның 15 октябрендәге Европа җирле үзидарә хартиясе (Россия Федерациясе өчен 1998 елның 1 сентябрендә үз көченә керде) нигезләмәсе тәңгәл килә, аның нигезендә җирле үзидарә органнары үзләренең вәкаләтләре өлкәсендәге һәм нинди дә булса башка хакимият органы карамагында булмаган теләсә нинди мәсьәлә буенча үз инициативасын гамәлгә ашыру өчен законда билгеләнгән чикләрдә тулысынча ирекле эш итәләр (4 статьяның 2 пункты).

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба шулай ук — 131-ФЗ номерлы Федераль закон) карамактагы мәсьәләләрне, вәкаләтләрне һәм компетенцияне кертеп, җирле үзидарәнең хокукый нигезен билгели һәм җирле үзидарә оештыруның гомуми принципларын җайга сала. Әлеге Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 1, 5 һәм 25 пунктларының, 17 статьясындагы үзара бәйле нигезләмәләре шәһәр округының җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә шәһәр округы бюджетын раслау һәм үтәүне, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген, аларның сакланышына контрольне гамәлгә ашыруны кертеп, шәһәр округы территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслауны кертәләр, шулай ук җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен күздә тоталар. Тиңдәш җайга салу «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясындагы 1 өлешенең 5 пунктында, 18 статьясында каралган.

Федераль һәм республика законнарының китерелгән нигезләмәләре Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставында (алга таба шулай ук — Устав) чагылыш тапкан, ул Казан шәһәр Думасы — Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органы вәкаләтләренә Казан шәһәре территориясендә законнар нигезендә һәркем өчен үтәү мәҗбүри булган кагайдәләрне билгеләү, шулай ук муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибен билгеләү турында карар кабул итү вәкаләтен керткән (28 статьяның 1 өлеше).

Уставның күрсәтелгән нигезләмәләренә таянып, Казан шәһәр Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы һәм 2013 елның 29 ноябрендәге 2-27 номерлы карарлары белән тиешенчә Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләре һәм Казан шәһәренең муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибе расланган.

Уставның 40 статьясындагы 14 өлешенең аерым нигезләмәләреннән күренгәнчә, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты вәкаләтләренә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының саклануын тәэмин итүгә муниципаль контроль башкару тәртибен билгеләү, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге, шулай ук җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын капиталь ремонтлау, ремонтлау, карап тотуга финанс чыгымнар нормативларын һәм күрсәтелгән максатларга җирле бюджет ассигнованиеләре күләмен исәпләү кагыйдәләрен раслау керә. Аталган вәкаләтләрне үтәү йөзеннән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты 2014 елның 13 августындагы 4735 номерлы карары белән гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын карап тоту тәртибен раслаган.

Шулай итеп, дәгъвалана торган норматив хокукый актларны

кабул итеп, Казан шәһәр Думасы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты федераль һәм республика законнары нигезендә үзләренә караган һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең үзара бәйле 116 (беренче өлеш) һәм 118 (беренче өлеш) статьяларына нигезләнгән вәкаләтләрен законлы рәвештә гамәлгә ашырганнар.

3. Татарстан Республикасын хокукый дәүләт дип игълан итеп, Татарстан Республикасы Конституциясе Татарстан Республикасына кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен иң зур хәзинә буларак тану, үтәү һәм яклау бурычын йөкли (1 статья, беренче өлеш; 2 статья). Шуның белән бергә Татарстан Республикасы Конституциясе әлеге конституциячел бурычның үтәлешен тәэмин итә торган гарантияләр исәбендә шундый нигезләмәләр беркетә ки, алар буенча Татарстан Республикасында кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгара яисә киметә торган законнар чыгарылмаска тиеш (58 статья, икенче өлеш); җирле үзидарә органнарының хокукый актлары Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килмәскә тиеш (24 статья, беренче өлеш).

Әлеге конституциячел нигезләмәләр шул исәптән җирле үзидарә органнарының Казан шәһәре чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау тәртибен регламентлаштыра торган норматив хокукый актларының эчтәлеге һәм мәгънәсенә нигез булалар.

Россия Федерациясе Конституция Судының 2016 елның 31 маендагы 14-П номерлы Карары эчтәлегеннән аңлашылганча, гомуми кулланылыштагы транспорт инфраструктурасын төзү һәм модернизацияләү, аннан куллану мөмкинлеге һәм аны тиешле хәлдә карап тоту гражданнарга Россия Федерациясе Конституциясе белән беркетелгән хокукларны һәм ирекләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле алшартлар тудыралар.

3.1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 52 статьясындагы 1 һәм 3 өлешләре нигезләмәләренә күрә һәр муниципаль берәмлекнең үз бюджеты бар (җирле бюджет); муниципаль берәмлекләрнең бюджет вәкаләтләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнә.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179.4 статьясындагы 1 өлеше юл фонды булдыруны күздә тота һәм аны гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген, шулай ук торак пунктлардагы күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренә керү юлларын капиталь ремонтлау һәм ремонтлауны финанс яктан тәэмин итү максатыннан тотылырга тиешле бюджетның бер өлеше буларак билгели; юл фондларына шул исәптән муниципаль юл фондлары карый.

Законнар белән бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында 2013 елның 29 ноябрендә Казан шәһәр Думасы тарафыннан 2014 елның 1 гыйнварыннан Казан шәһәренең муниципаль юл фондын (алга таба шулай ук — юл фонды) бул-

дыру турында карар кабул ителгән һәм Казан шәһәренең муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибе расланган. Әлеге Тәртип буенча Казан шәһәренең муниципаль юл фонды — гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген, Казан шәһәрендәге күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренә керү юлларын капиталь ремонтлау һәм ремонтлауны финанс яктан тәэмин итү максатыннан тотылырга тиешле Казан шәһәре бюджетының бер өлеше (I кисәк); юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләме Казан шәһәр Думасының чираттагы финанс елына һәм план чорына Казан шәһәре бюджеты турындагы карары белән раслана (2.1 пункт). Шул ук вакытта Тәртипнең 3.1 пунктында әлеге фондның бюджет ассигнованиеләрен куллану юнәлешләренең тулы исемлеге билгеләнгән, атап әйткәндә, алар: гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын һәм алардагы ясалма корылмаларны проектлаштыру, төзү, реконструкцияләү; гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын һәм алардагы ясалма корылмаларны капиталь ремонтлау һәм ремонтлау; гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын һәм алардагы ясалма корылмаларны карап тоту; Казан шәһәрендәге күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренә керү юлларын капиталь ремонтлау һәм ремонтлау.

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр керту хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба шулай ук — 257-ФЗ номерлы Федераль закон) 17 һәм 18 статьяларындагы үзара бәйле нигезләмәләренең мәгънәсе буенча автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау тәртибе Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары һәм муниципаль хокукый актлар, шулай ук техник регламентлар белән билгеләнә, соңгыларының таләпләре нигезендә автомобиль юлларының хуҗалары тарафыннан аларның техник торышын бәяләү үткәрелә; шул ук вакытта автомобиль юлларының транспорт-эксплуатация сыйфатламалары техник регламентлар таләпләренә туры килмәгән очракта автомобиль юлларына капиталь ремонт яки ремонт ясала, ә автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау буенча эшләр классификациясе башкарма хакимиятнең дәүләт сәясәтен булдыру һәм юл хуҗалыгы өлкәсендә норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль органы тарафыннан билгеләнә.

Автомобиль юллары, шәһәрләр һәм башка торак пунктларның урамнары һәм юлларының эксплуатацияләнү торышының хәрәкәт иминлеген тәэмин итү шартлары буенча мөмкин булган чик күрсәткечләрен һәм исемлеген, шулай ук юл хәрәкәтен

оештыручы техник чараларның эксплуатацияләнү торышына таләпләр Россия Федерациясе Госстандартының 1993 елның 11 октябрендәге 221 номерлы карары белән расланган «ГОСТ Р 50597-93. Автомобиль юллары һәм урамнар. Юл хәрәкәте иминлегеен тәэмин итү шартлары буенча мөмкин булган эксплуатация торышына таләпләр» Россия Федерациясе Дәүләт стандарты белән билгеләнгән.

Җирле әһәмияттәге юлларның торышын аларны карап тотканда билгеләнгән техник регламентларга һәм башка норматив документларга туры килүен тәэмин итү бурычы 257-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 3 өлешенең һәм «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба шулай ук — 196-ФЗ номерлы Федераль закон) 12 статьясындагы 2 пунктының үзара бәйле нигезләмәләренә күрә вәкаләтле җирле үзидарә органнарына йөкләнгән. 196-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы эчтәлегеннән аңлашылганча, юллар торышының техник регламентларга һәм башка норматив документларга туры килүе тиешле органнар катнашында башкарыла торган юлларны контроль карау яки тикшерү актлары белән расланган. Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2009 елның 27 августындагы 150 номерлы боерыгы белән расланган Автомобиль юлларының техник торышын бәяләүне үткәрү тәртибенең 3 пунктындагы дүртенче абзацы һәм 4 пункты буенча гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларының техник торышын бәяләү автомобиль юлларын куллану һәм юл эшчәнлеген башкару өлкәсендәге җирле үзидарә органы яки ул вәкаләтләгән оешма тарафыннан үткәрелә; бәяләү кимендә елга бер тапкыр үткәрелә.

Шулай итеп, юл фондыннан акчалар бүлеп бирүнең төп критерийлары булып гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларының, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренең, квартал эчендәге машина юлларының техник торышының норматив таләпләргә туры килмәве, шулай ук юл полотносының саклануын һәм торгызылуын тәэмин итүнең объектив кирәклеге тора.

Тәртипнең 3.3 пунктын китерелгән норматив нигезләмәләр белән үзара бәйләнештә анализлау шуны күрсәтә: аның белән билгеләнгән хокукый җайга салу үзенең хокукый табигате буенча гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларының, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренең, квартал эчендәге машина юлларының техник торышын бәяләү нәтиҗәләре нигезендә, Казан шәһәре бюджетының финанс мөмкинлекләрен исәпкә алып, юл фонды акчаларын бүлү һәм нәтиҗәле куллану буенча оештыру функцияләрен башкара торган конкрет җирле үзидарә органын билгеләүгә юнәлгән.

Бу юл фонды бюджет ассигнованиеләрен бүлү һәм ремонтланулары юл фондыннан финансланырга тиешле гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын,

күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен, квартал эчендәге машина юлларын сайлап алу ирекле түгел дигәнне аңлата, чөнки Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләре күләмен бүлү турында карар кабул иткән вакытта, бүленә торган акчаларның каралган максатларга ярашлы булу принцибын исәпкә алып, бөтен мәсьәләләр комплексын, шул исәптән аларның техник торышын бәяләү белән бәйле булганнарын өйрәнергә тиеш.

Бәян ителгәннәр нигезендә Тәртипнең 3.3 пункты белән билгеләнгән хокукый җайга салу, юл фонды бюджет ассигнованиеләренең расланган күләмен чыгымнарның максатчан юнәлешләре буенча бүлү критерийларын кертеп, юридик көче аларны бары тик бергә куллану юлы белән генә гамәлгә ашырыла торган бердәм нормалар комплексыннан чыга һәм кеше һәм гражданның, шул исәптән мөрәҗәгать итүчеләрнең конституциячел хокукларын һәм ирекләрен боза торган итеп карала алмый.

Шул ук вакытта Россия Федерациясе Конституция Суды үзенең карарларында берничә тапкыр билгеләп үткәнчә, җирле үзидарәнең конституциячел билгеләнеше халыкның уртак көнкүреше территориясе буларак муниципаль берәмлек чикләрендә социаль-икътисади бурычларны чишү белән беррәттән кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен саклау һәм яклау, кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш өчен шартлар тудыру бурычларын нәтиҗәле гамәлгә ашыруда чагыла (2011 елның 29 мартындагы 2-П номерлы, 2015 елның 13 октябрендәге 26-П номерлы, 2016 елның 26 апрелендәге 13-П номерлы карарлар).

Моңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция суды шуңа игътибар итә: дәгъвалана торган нигезләмәне куллану гражданнарга бирелгән лаеклы тормыш хокукы асылына шул исәптән гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен, квартал эчендәге машина юлларын тиешле хәлдә карап тотуны тәэмин итү өлешендә кагылмаска, шулай ук закон өстенлеге, тигезлек һәм гаделлек, законга һәм дәүләт гамәлләренә гражданнарның ышанычын саклау принципларын бозуны булдырмаска тиеш. Казан шәһәренең юл фонды бюджет ассигнованиеләре бүленешенә нигез булган шартлар һәм критерийларның тулырак һәм тәфсиллерәк исемлеген турыдан-туры дәгъвалана торган актта беркетү карала торган хокукый җайга салуның билгелелегенә, ачыклыгына һәм мәгънә берлегенә ярдәм итәр иде. Мондый алым Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясенә (2001 елның 13 декабрендәге 16-П номерлы, 2004 елның 17 июнендәге 12-П номерлы һәм 2008 елның 27 ноябрендәге 11-П номерлы карарлар), шулай ук Кеше хокуклары буенча Европа Судының практикасына (2007 елның 24 маендагы «Игнатов (Ignatov) Россия Федерациясенә каршы» эше; 2007 елның 24 маендагы «Владимир Соловьев (Vladimir Solovyev) Россия Федерациясенә каршы» эше буенча карарлар) туры килә.

3.2. 131-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 18 абзацыннан аңлашылганча, шәһәр округы территориясен төзекләндерү — шәһәр округы территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән каралган территорияне карап тоту, шулай ук төзекләндерү объектларын проектлау һәм урнаштыру буенча гражданнарның яшәү шартларының уңайлыгын тәэмин итү һәм күтәрүгә, территориянең санитар һәм эстетик торышын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар комплексы ул.

Җирле әһәмияткә ия булган юлларны карап тотуга да таләпләр билгели торган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләре әлеге Федераль законны үтәү йөзеннән эшләнгән, үзләренең максатчан билгеләнеше һәм юридик табигате буенча гомумән шәһәр округы территориясен төзекләндерүне оештыруга юнәлгән.

Кагыйдәләрнең нигезләмәләре Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын һәм төзекләндерү элементларын карап тоту буенча эшләр башкару регламентында үсеш алган. Регламентка анализ ясау шуны күрсәтә: үзенең хокукый мәгънәсе буенча ул Казан шәһәренең автомобиль юлларын җәйге һәм кышкы чорда аларны киртәсез эксплуатацияләүне тәэмин итү өчен тиешле тәртиптә һәм чисталыкта тотуга юнәлдерелгән оештыру-процедура механизмы булып тора.

Мөрәҗәгать итүчеләр китергән дәлилләр күрсәткәнчә, үзләренең конституциячел хокукларының бозылуын алар турыдан-туры дәгъвалана торган Кагыйдәләрнең текстында, шулай ук Регламентта гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен, квартал эчендәге машина юлларын ремонтлау буенча бөтен эшләр исемлеген тәфсилләп регламентлаштыра торган конкрет нигезләмәләрнең булмавына бәйлиләр.

Шул ук вакытта Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясе мәгънәсе буенча хокукый җайга салуның билгелелек дәрәҗәсе хокукый күрсәтмәләрнең үзара бәйләнешенең бөтен системасын ачыклау юлы белән һәм гражданнарның гамәлгә ашырыла торган хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре үзенчәлекләрен исәпкә алып бәяләнергә тиеш (2014 елның 23 сентябрендәге 24-П номерлы, 2015 елның 17 февралендәге 2-П номерлы һәм 2015 елның 16 июлендәге 22-П номерлы карарлар).

Бу Кагыйдәләрдә дә, Регламентта да автомобиль юлларын ремонтлау процедурасын турыдан-туры җайга сала торган махсус нормаларның булмавы үзеннән-үзе Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килә торган итеп карала алмаганны аңлата, чөнки андый ремонтның башка норматив хокукый актлар белән, аерым алганда, Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының юл эшләре күләмен планлаштырганда куллану өчен каралган һәм юл эшләре составын һәм төрләрен билгели торган Автомобиль юлларын капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту буенча эшләр классификациясен раслаган 2012 елның 16 ноябрендәге 402 номерлы боерыгы белән каралган тәртиптә башкару мөмкинлеген һәм кирәклеген шик астына куймый.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды

түбәндәгене билгеләп үтәргә кирәк дип саный. Кагыйдәләрнең 6 пунктындагы илленче абзацның һәм 54 пунктындагы дәгъвалана торган 1 пунктчасының үзара бәйле нигезләмәләренә күрә юллар территорияләрен карап тоту юлларның транспорт-эксплуатация торышын тәртиптә тоту буенча эшләр комплексы булып тора һәм үз эченә бүтән эшләрдән башка тагын юлларны, тротуарларны, ясалма юл корылмаларын, квартал эчендәге машина юлларын ремонтлауны кертә.

257-ФЗ номерлы Федераль закон исә автомобиль юлын карап тоту һәм ремонтлау төшенчәләрен аера. Шулай, күрсәтелгән Федераль законның 3 статьясы мәгънәсенә күрә автомобиль юлын карап тоту — автомобиль юлының техник торышын тиешле тәртиптә тоту, аның техник торышын бәяләү, шулай ук юл хәрәкәте иминлеген оештыру һәм тәэмин итү буенча эшләр комплексы (12 пункт), ә автомобиль юлын ремонтлау — автомобиль юлының транспорт-эксплуатация сыйфатламаларын яңадан торгызу буенча эшләр комплексы, аларны башкарганда автомобиль юлы ышанычлылыгы һәм иминлегенең конструктив һәм башка сыйфатламаларына кагылмыйлар (11 пункт).

Татарстан Республикасы Конституция суды, Кагыйдәләрнең 54 пунктындагы 1 пунктчасы белән юлны ремонтлау андый юлны карап тотуның состав өлеше була торган хокукый җайга салуны билгеләү гамәлдәге федераль законнар белән җирле үзидарә органнарына бирелгән әлеге өлкәдәге хокук чыгару вәкаләтләре чикләреннән чыкмый һәм Кагыйдәләрнең норматив нигезләмәләренә юлларны карап тоту һәм ремонтлау мәсьәләләрендә бердәм һәм универсаль булу сыйфатын бирү кирәклеге белән аңлатыла, дип саный.

Ләкин мондый алым Кагыйдәләрнең гомуми таләпләрен үстерү һәм конкретлаштыру максатларында кабул ителә торган хокукый актлар дәрәҗәсендә дә логик-хокукый бәйләнешнең саклануын таләп итә. Регламентның 2.1 һәм 2.2 бүлекчәләре эчтәлегеннән аңлашылганча, алар максаты автомобиль юлларының транспорт-эксплуатация сыйфатламаларын яңадан торгызу булган шундый юлларны ремонтлауга түгел, ә автомобиль юлларын тиешле тәртиптә һәм чисталыкта тотуга һәм аларны җәйге һәм кышкы чорда киртәсез эксплуатацияләүгә генә юнәлдерелгән чаралар исемлеген регламентлаштыралар.

Моңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция суды шуңа игътибар итә: Регламентның дәгъвалана торган норматив нигезләмәләренең Кагыйдәләрнең 54 пунктындагы юллар ремонтлауны аларны карап тоту буенча чаралар исемлегенә кертә торган 1 пунктчасы белән логик-хокукый бәйләнеше Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына, гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларының, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренең, квартал эчендәге машина юлларының саклануын тәэмин итү мәсьәләләрендә бердәм алым кулланып, карала торган хокукый мөнәсәбәтләр өлкәсен кирәгенчә тулысынча җайга салуны йөкли. Бу Казан шәһәре муниципаль берәмлеге

Башкарма комитетының норматив хокукый акт төрен, андый хокукый җайга салуны билгеләү өчен формалар һәм ысуллар сайлауга дискрецион вәкаләтләренә кагылмый.

Шулай итеп, «Казан шәһәренең муниципаль юл фонды турында» Казан шәһәр Думасының 2013 елның 29 ноябрендәге 2-27 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибенең 3.3 пунктының; Казан шәһәр Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренең 54 пунктындагы 1 пунктчасының; «Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын карап тоту тәртибе турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 13 августындагы 4735 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын һәм төзекләндерү элементларын карап тоту буенча эшләр башкару регламентының 2.1 һәм 2.2 бүлекчәләренең дәгъвалана торган хокукый нигезләмәләре системалы берлектә торалар һәм бердәм хокукый мөнәсәбәтләр комплексына кагылалар, үзләреннән-үзе кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын, шул исәптән мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын юкка чыгармыйлар, киметмиләр һәм башкача бозмыйлар һәм шуның белән Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче өлеш) һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына каршы килмиләр.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71 һәм 73 статьяларына, 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

карар чыгарды:

1. «Казан шәһәренең муниципаль юл фонды турында» Казан шәһәр Думасының 2013 елның 29 ноябрендәге 2-27 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибенең 3.3 пунктын; Казан шәһәр Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренең 54 пунктындагы 1 пунктчасын; «Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын карап тоту тәртибе турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 13 августындагы 4735 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын һәм төзекләндерү элементларын карап тоту буенча эшләр башкару регламентының 2.1 һәм 2.2 бүлекчәләрендәге аерым нигезләмәләрне Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм баш-

ка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

3. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясы буенча бу Карар «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 72-П

Татарстан Республикасы
Конституция суды

ИМЕНЕМ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

по делу о проверке конституционности пункта 3 части 1 статьи 74 и абзаца третьего части 9 статьи 79 Устава Пестречинского муниципального района Республики Татарстан, принятого решением Совета Пестречинского муниципального района Республики Татарстан от 21 мая 2015 года № 14/235; подпункта 3.4.1 пункта 3.4 и раздела 3 Положения о порядке создания, реорганизации и ликвидации образовательных организаций Пестречинского муниципального района, утвержденного постановлением Исполнительного комитета Пестречинского муниципального района Республики Татарстан от 30 мая 2016 года № 762; подпункта 8.1 пункта 8 и подпункта 5 пункта 11 Положения о комиссии по оценке последствий принятия решения о реорганизации, ликвидации, изменении статуса, реконструкции, модернизации, изменении назначения образовательной организации Пестречинского муниципального района, утвержденного постановлением Исполнительного комитета Пестречинского муниципального района Республики Татарстан от 8 июня 2016 года № 881; пунктов 1.3, 2.14 и 2.19 Порядка проведения оценки последствий принятия решения о реорганизации или ликвидации образовательной организации, находящейся в ведении Республики Татарстан, муниципальной образовательной организации, включая критерии этой оценки (по типам данных образовательных организаций), в том числе порядка создания комиссии по оценке последствий такого решения и подготовки ею заключений, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 5 февраля 2014 года № 63; а также названных Устава и постановлений Исполнительного комитета Пестречинского муниципального района Республики Татарстан в целом в связи с жалобами граждан Г.И. Волковой и Р.Х. Маликова

28 апреля
2017 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

руководствуясь статьей 109 (часть четвертая) Конституции Республики Татарстан, частями пятой и девятой статьи 3, частью первой и пунктом 1 части второй статьи 39, статьями 68, 83, 100, 101, 103 и 113 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан»,

рассмотрел в открытом выездном судебном заседании дело о проверке конституционности пункта 3 части 1 статьи 74 и абзаца третьего части 9 статьи 79 Устава Пестречинского муниципального района Республики Татарстан, принятого решением Совета Пестречинского муниципального района Республики Татарстан от 21 мая 2015 года № 14/235; подпункта 3.4.1 пункта 3.4 и раздела 3 Положения о порядке создания, реорганизации и ликвидации образовательных организаций Пестречинского муниципального района, утвержденного постановлением Исполнительного комитета Пестречинского муниципального района Республики Татар-

стан от 30 мая 2016 года № 762; подпункта 8.1 пункта 8 и подпункта 5 пункта 11 Положения о комиссии по оценке последствий принятия решения о реорганизации, ликвидации, изменении статуса, реконструкции, модернизации, изменении назначения образовательной организации Пестречинского муниципального района, утвержденного постановлением Исполнительного комитета Пестречинского муниципального района Республики Татарстан от 8 июня 2016 года № 881; пунктов 1.3, 2.14 и 2.19 Порядка проведения оценки последствий принятия решения о реорганизации или ликвидации образовательной организации, находящейся в ведении Республики Татарстан, муниципальной образовательной организации, включая критерии этой оценки (по типам данных образовательных организаций), в том числе порядка создания комиссии по оценке последствий такого решения и подготовки ею заключений, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 5 февраля 2014 года № 63; а также названных Устава и постановлений Исполнительного комитета Пестречинского муниципального района Республики Татарстан в целом по порядку их официального опубликования.

Поводом к рассмотрению дела явились жалобы граждан Г.И. Волковой и Р.Х. Маликова. Основанием к рассмотрению дела явилась обнаружившаяся неопределенность в вопросе о том, соответствуют ли оспариваемые заявителями нормативные положения Конституции Республики Татарстан.

Поскольку жалобы касаются одного и того же предмета, Конституционный суд Республики Татарстан, руководствуясь частью второй статьи 50 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», соединил дела по этим жалобам в одном производстве.

Заслушав сообщение судьи-докладчика А.Р. Шакараева, объяснения сторон — граждан Г.И. Волковой и Р.Х. Маликова, представителей органов, издавших оспариваемые нормативные правовые акты, — начальника юридического отдела Министерства образования и науки Республики Татарстан Д.Д. Абдуллина, начальника юридического отдела аппарата Совета Пестречинского муниципального района Республики Татарстан С.М. Павловой, специалиста, приглашенного в судебное заседание по ходатайству представителя Совета и Исполнительного комитета Пестречинского муниципального района Республики Татарстан, — ведущего специалиста по правовым вопросам МУП «Центр капитального строительства Пестречинского района Республики Татарстан» Э.А. Жигановой, специалистов, приглашенных в судебное заседание по инициативе Конституционного суда Республики Татарстан, — начальника отдела общего образования и итоговой аттестации обучающихся Управления общего образования Министерства образования и науки Республики Татарстан Л.И. Саубановой, начальника отдела по вопросам нормативных правовых актов субъекта Российской Федерации и ведения федерального регистра, ведения реестра муниципальных образований, регистрации и ведения реестра уставов муниципальных

образований Управления Министерства юстиции Российской Федерации по Республике Татарстан Р.Н. Рахимова, выступления приглашенных в судебное заседание: представителя Президента Республики Татарстан — главного советника отдела по законопроектной работе Государственно-правового управления Президента Республики Татарстан Л.К. Валиуллиной, представителя Государственного Совета Республики Татарстан — начальника Правового управления Аппарата Государственного Совета Республики Татарстан М.Б. Сунгатуллина, представителя Кабинета Министров Республики Татарстан — Правительства Республики Татарстан — заведующего сектором административного права и систематизации законодательства Правового управления Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан К.А. Козновой, представителя Председателя Верховного суда Республики Татарстан — судьи Верховного суда Республики Татарстан Ш.Ш. Гафиятуллина, представителя Председателя Арбитражного суда Республики Татарстан — заместителя начальника отдела анализа и обобщения судебной практики Арбитражного суда Республики Татарстан Т.Р. Гиззятова, представителя Прокурора Республики Татарстан — прокурора отдела по надзору за законностью нормативных правовых актов Управления по надзору за исполнением федерального законодательства прокуратуры Республики Татарстан А.А. Яруллина, представителя Уполномоченного по правам человека в Республике Татарстан — начальника отдела по вопросам восстановления прав граждан аппарата Уполномоченного по правам человека в Республике Татарстан А.Г. Бартенева, представителя Уполномоченного по правам ребенка в Республике Татарстан — ведущего консультанта отдела по защите прав и законных интересов детей аппарата Уполномоченного по правам ребенка в Республике Татарстан А.Н. Хамитовой, исследовав представленные документы и иные материалы, Конституционный суд Республики Татарстан

установил:

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратились граждане Г.И. Волкова и Р.Х. Маликов с жалобами на нарушение их конституционных прав и свобод пунктом 3 части 1 статьи 74 и абзацем третьим части 9 статьи 79 Устава Пестречинского муниципального района Республики Татарстан, принятого решением Совета Пестречинского муниципального района Республики Татарстан от 21 мая 2015 года № 14/235 (далее также — Устав); подпунктом 3.4.1 пункта 3.4 и разделом 3 Положения о порядке создания, реорганизации и ликвидации образовательных организаций Пестречинского муниципального района, утвержденного постановлением Исполнительного комитета Пестречинского муниципального района Республики Татарстан от 30 мая 2016 года № 762 (далее также — Положение); подпунктом 8.1 пункта 8 и подпунктом 5 пункта 11 Положения о комиссии по оценке последствий принятия решения о реорганизации, ликвидации, изменении статуса, реконструкции, модернизации, изменении

назначения образовательной организации Пестречинского муниципального района, утвержденного постановлением Исполнительного комитета Пестречинского муниципального района Республики Татарстан от 8 июня 2016 года № 881 (далее также — Положение о комиссии); пунктами 1.3, 2.14 и 2.19 Порядка проведения оценки последствий принятия решения о реорганизации или ликвидации образовательной организации, находящейся в ведении Республики Татарстан, муниципальной образовательной организации, включая критерии этой оценки (по типам данных образовательных организаций), в том числе порядка создания комиссии по оценке последствий такого решения и подготовки ею заключений, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 5 февраля 2014 года № 63 (далее также — Порядок); а также названными Уставом и постановлениями Исполнительного комитета Пестречинского муниципального района Республики Татарстан в целом.

Согласно пункту 3 части 1 статьи 74 Устава руководитель Исполнительного комитета Пестречинского муниципального района Республики Татарстан издает постановления и распоряжения руководителя Исполнительного комитета Пестречинского муниципального района Республики Татарстан. Абзацем третьим части 9 статьи 79 Устава определено, что официальное опубликование (обнародование) муниципальных правовых актов осуществляется посредством размещения текста правового акта или проекта правового акта на официальном сайте Пестречинского муниципального района Республики Татарстан на Портале муниципальных образований Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети Интернет, а также на «Официальном портале правовой информации Республики Татарстан».

Разделом 3 Положения установлен порядок реорганизации образовательной организации. Подпунктом 3.4.1 пункта 3.4 Положения предусмотрено, что при необходимости реорганизации Исполнительный комитет Пестречинского муниципального района Республики Татарстан проводит оценку последствий принятия решения о реорганизации муниципальной образовательной организации в соответствии с Федеральным законом от 24 июля 1998 года № 124-ФЗ «Об основных гарантиях прав ребенка в Российской Федерации», постановлением Правительства Российской Федерации от 6 февраля 2014 года № 84 «Об утверждении Правил проведения оценки последствий принятия решения о реорганизации или ликвидации федеральной государственной образовательной организации и Правил создания комиссии по оценке последствий принятия решения о реорганизации или ликвидации федеральной государственной образовательной организации и подготовки указанной комиссией заключений».

Подпункт 8.1 пункта 8 Положения о комиссии предусматривает критерии, на основании которых комиссия по оценке последствий принятия решения о реорганизации, ликвидации, изменении статуса, реконструкции, модернизации, изменении назначения образовательной организации Пестречинского муни-

ципального района проводит оценку последствий принятия решений о реорганизации или ликвидации образовательной организации, относящейся к типу общеобразовательных организаций.

Подпункт 5 пункта 11 Положения о комиссии определяет, что оценка последствий принятия решения о реорганизации или ликвидации образовательной организации проводится на основании решения собрания жителей сельского поселения.

Пунктами 1.3, 2.14 и 2.19 Порядка установлены механизм проведения оценки последствий принятия решения о реорганизации или ликвидации образовательной организации и содержание заключения комиссии по оценке последствий принятия решения о реорганизации или ликвидации образовательной организации.

Как следует из жалоб, дополнений и приложенных к ним копий документов, постановлением Исполнительного комитета Пестречинского муниципального района Республики Татарстан от 30 июня 2016 года № 931 муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Белкинская основная общеобразовательная школа» Пестречинского муниципального района Республики Татарстан (далее — Белкинская школа) было реорганизовано путем присоединения в качестве филиала к муниципальному бюджетному общеобразовательному учреждению «Ленино-Кокушкинская средняя общеобразовательная школа» Пестречинского муниципального района Республики Татарстан с реализацией программы начального общего образования. При этом, как указывают заявители, не было учтено мнение жителей села Белкино и педагогического состава Белкинской школы, которые были против такой реорганизации.

Граждане Г.И. Волкова и Р.Х. Маликов полагают, что принятие решения о реорганизации Белкинской школы стало возможным, поскольку органами местного самоуправления Пестречинского муниципального района Республики Татарстан при издании оспариваемых нормативных правовых актов допущен ряд грубых нарушений, приводящих к ограничению конституционных прав и свобод граждан, в том числе заявителей.

Так, они указывают, что раздел 3 Положения не содержит требования о необходимости учета мнения жителей сельского поселения при принятии решения о реорганизации или ликвидации муниципальной общеобразовательной организации, расположенной в данном сельском поселении, обязательный характер которого вытекает из содержания положений части 12 статьи 22 Федерального закона «Об образовании в Российской Федерации» и части 4 статьи 13 Закона Республики Татарстан «Об образовании».

Граждане Г.И. Волкова и Р.Х. Маликов также отмечают, что подпункт 3.4.1 пункта 3.4 Положения определяет в качестве нормативной основы своего регулирования положения федерального законодательства, которые распространяются только на федеральные государственные образовательные организации. Между тем, поскольку рассматриваемое правовое регулирование осуществляется в отношении муниципальной образовательной

организации, оспариваемое Положение, по их мнению, должно основываться на нормах постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 5 февраля 2014 года № 63.

Оспаривая подпункт 5 пункта 11 Положения о комиссии, заявители указывают, что учет мнения граждан сельского поселения в соответствии со статьей 31 Федерального закона от 6 октября 2003 года № 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации» (далее — Федеральный закон № 131-ФЗ) проводится в форме опроса, а не в форме собрания жителей сельского поселения, как это предусмотрено оспариваемым подпунктом.

В обоснование своей позиции относительно неконституционности подпункта 8.1 пункта 8 Положения о комиссии граждане Г.И. Волкова и Р.Х. Маликов отмечают, что Исполнительный комитет Пестречинского муниципального района Республики Татарстан установил в нем собственные критерии оценки последствий принятия решения о реорганизации образовательной организации, которые не согласуются с критериями, предусмотренными нормативным правовым актом, имеющим большую юридическую силу, а именно обжалуемым Порядком, утвержденным постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 5 февраля 2014 года № 63.

Кроме того, заявители полагают, что предусмотренное пунктами 1.3, 2.14 и 2.19 указанного Порядка правовое регулирование, в свою очередь, допускает возможность произвольного применения данных норм, поскольку четко не регламентирует механизм принятия комиссией заключения в тех случаях, когда предполагаемая реорганизация образовательной организации не отвечает всем установленным критериям. По их мнению, пункты 2.14 и 2.19 не предусматривают необходимость указания в таком заключении комиссии всех критериев, определенных пунктом 1.3 Порядка, а также каким должно быть заключение в случаях, когда с одними критериями реорганизация или ликвидация согласуется, а с другими нет.

Граждане Г.И. Волкова и Р.Х. Маликов также обращают внимание на то, что была нарушена процедура опубликования Устава и оспариваемых постановлений Исполнительного комитета Пестречинского муниципального района Республики Татарстан.

Заявители считают, что Устав не опубликован официально для всеобщего сведения в установленном порядке, поскольку на «Официальном портале правовой информации Республики Татарстан» (далее также — Портал) размещено только решение Совета Пестречинского муниципального района Республики Татарстан от 21 мая 2015 года № 14/235 «О принятии Устава Пестречинского муниципального района Республики Татарстан», а самого текста Устава как на Портале, так и в других источниках официального опубликования не содержится.

Граждане Г.И. Волкова и Р.Х. Маликов также отмечают, что на официальном сайте района на Портале муниципальных образований Республики Татарстан в информационно-телекомму-

Шушы ук нигезләр буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 30 маендагы 762 номерлы карарын һәм аның белән расланган Нигезләмәне районның рәсми сайтында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштырганда рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе үтәлмәве турында нәтиҗә ясый. Мондый нәтиҗә югарыда күрсәтелгән рәсми басылып чыгу чыганакларында урнаштырылганда күрсәтелгән әлеге карарның исеме акт текстында булган исем белән туры килмәүгә бәйле. Шуңа бәйле рәвештә актның график сурәтендә аны районның рәсми сайтында һәм Порталда реквизитлары күрсәтелгән акт буларак таныта торган нинди дә булса башка билгеләр булмаганлыгын исәпкә алып, аны шундый рәвештә урнаштыру нәкъ менә дәгъвалана торган муниципаль хокукый акт рәсми басылып чыккан мы икәнен төгәл билгеләү мөмкинлеген бирми һәм, димәк, дәгъвалана торган акт эчтәлеген гражданнар игътибарына җиткерү функциясен тулысынча тәэмин итә алмый. Киресенчә булса, Татарстан Республикасы Конституция суды элегрәк күрсәткәнчә, җирле үзидарә органнарының, алар тарафыннан билгеләнгән күрсәтмәләрне үз эченә алган норматив хокукый актларны бастырып чыгару буенча закон таләпләре үтәлмәгәндә, әлеге күрсәтмәләрнең үтәлешен таләп итүе мөмкин булыр иде, бу хокукый дәүләт, хәбәрдарлык, хокук өстенлеге, тигезлек һәм гаделлек конституциячел принципларына туры килми (2015 елның 19 мартындагы 61-П номерлы карар).

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 30 маендагы 762 номерлы карары һәм аның белән расланган Нигезләмә тулысынча, алар билгеләнгән тәртиптә гомуми танышу өчен рәсми рәвештә басылып чыкмаганга күрә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, аның 24 статьясына (өченче өлеш), шулай ук, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма

комитеты гражданнарның аларның хокукларына, ирекләренә һәм законлы мәнфәгатьләренә кагыла торган җирле үзидарә органнары кабул иткән карарлар белән танышу хокукларын тәэмин итү буенча бурычын үтәмәгәнгә күрә, аның 48 статьясына (икенче өлеш) туры килми.

Татарстан Республикасы Конституция суды аеруча шуңа игътибар итә: норматив хокукый актларны рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибен үтәү — кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклау механизмының аерылгысыз элементы, шуңа күрә кабул ителә торган актның тулы һәм төгәл реквизитларын аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге тиешле рәсми ресурсларда бастырып чыгарганда (халыкка җиткергәндә) шул исәптән график сурәтендә күрсәтү андый яклауның нәтиҗәлелеген күтәрүгә ярдәм итә һәм ул мәҗбүри.

Мондый алым Россия Федерациясе Конституция Суды позициясенә дә тулысынча туры килә, ул үзләренең эчтәлеге һәм (яки) формасы буенча хокукый нормаларның формаль билгеләнеше, төгәллеге, ачыклыгы, бер мәгънәдә булуы һәм гамәлдәге хокукый җайга салу системасында аларның яраклашканлыгы критерийларына җавап бирми торган закон нигезләмәләре аларны төрле мәгънәдә аңлату һәм ирекле куллану мөмкинлеген булдыралар һәм шуның белән гражданнарның конституциячел хокукларын бозуга китерәләр дип берничә тапкыр билгеләп үтте (2012 елның 29 июнендәге 16-П номерлы, 2013 елның 14 маендагы 9-П номерлы карарлар һ.б.).

3. Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 30 маендагы 762 номерлы карарын Татарстан Республикасы Конституциясенә тулы күләмдә туры килми дип тану әлеге норматив хокукый акт, үз көченә кермәгән буларак, хокукый нәтиҗәләргә китерми һәм тиешле хокукый мөнәсәбәтләрне җайга салу өчен нигез булып тора алмый дигәнне аңлата.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 100 һәм 101 статьялары мәгънәсе буенча норматив хокукый актлардагы нормалар эчтәлегенең конституциячеллеген тикшерү мөрәҗәгатьтә үз көченә кергән норматив нигезләмәләргә дәгъва белдерелгәндә генә мөмкин.

Димәк, гражданнар Г.И. Волкова һәм Р.Х. Мәликовның Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 30 маендагы 762 номерлы карары белән расланган Питрәч муниципаль районы белем бирү оешмаларын булдыру, үзгәртеп оештыру һәм бетерү тәртибе турында нигезләмәнең 3.4 пунктындагы 3.4.1 пунктчасы һәм 3 бүлеге белән конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаяте карала алмый һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 63 статьясы нигезендә әлеге эш күрсәтелгән өлешендә туктатылырга тиеш.

4. Татарстан Республикасы Конституциясенең 10 һәм 116 (бе-

ренче өлеш) статьялары нигезендә Татарстан Республикасында үз вәкаләтләре чикләрендә мөстәкыйль һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне халыкның хәл итүен тәэмин итә торган җирле үзидарә таныла һәм гарантияләнә. Шундый ук нигезләмәләр Россия Федерациясе Конституциясенең 12 һәм 130 (1 өлеш) статьяларында да беркетелгән.

Җирле үзидарә оештыруның гомуми хокукый, оештыру һәм икътисади принципларын беркетә торган 131-ФЗ номерлы Федераль законда муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан устав кабул ителә, анда шул исәптән җирле үзидарәнең сайлаулы һәм башка органнарының һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының исемнәре һәм вәкаләтләре; муниципаль хокукый актларның төрләре, аларны кабул итү (чыгару), рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм аларның үз көченә керү тәртибе билгеләнергә тиеш дип каралган (44 статьяның 1 өлешендәге 5 һәм 6 пунктлары, 3 өлеше). Тиңдәш нормалар шулай ук «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясындагы 1 өлешенең 5, 6 пунктлары һәм 3 өлеше белән каралган.

Шулай итеп, Уставның дәгъвалана торган нормаларында карала торган муниципаль районның җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары кабул итә торган муниципаль хокукый актлар төрләрен, шулай ук аларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) тәртибен беркетеп, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы — Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы җирле үзидарә турында федераль законнар буенча да, республика законнары буенча да үзенә караган вәкаләтне гамәлгә ашырган.

4.1. Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясе буенча федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларының легальлеге аларда билгеле, законга каршы килмәгән норматив эчтәлекнең (гомуми кагыйдәнең) булуын гына таләп итмичә, тиешле законлы форманы, кабул итү һәм халыкка җиткерү тәртибен үтәүне дә күздә тота; гамәлдәге хокукый җайга салу системасында андый норматив актны суд тарафыннан тикшерү үз эченә аның норматив күрсәтмәләренең эчтәлеге, акт формасы, шулай ук аны чыгарган субъект, кабул итү, бастыру һәм гамәлгә кертү тәртибе буенча федераль законга ярашлы булу-булмавын билгеләүне кертә (2015 елның 31 мартындагы 6-П номерлы Карар).

Администрация башлыгы — муниципаль районның башкарма комитеты җитәкчесе чыгара торган хокукый актлар формасына кагылышлы мәсьәлә Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметын тәшкил иткән иде инде, ул 2015 елның 23 июнендәге 63-П номерлы карарында билгеләгәнчә, 131-ФЗ номерлы Федераль законның үтәлешен тәэмин итү йөзеннән кабул ителгән «“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр керту хакында» 2009 елның 4 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан

Республикасы Законы белән яңа хокукый җайга салу кертелгән, аның нигезендә җирле администрацияләр башлыклары чыгара торган хокукый актлар җирле администрацияләр карарлары һәм күрсәтмәләре формасында кабул ителәләр. Моннан чыгып, суд закон таләпләренә нигезләнгән әһәмиятле процессуаль элемент буларак җирле администрациянең хокукый актының закон белән билгеләнгән әлеге формасын Татарстан Республикасындагы барлык муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан мәҗбүри үтәү тиешлегенә һәм Татарстан Республикасындагы муниципаль берәмлекләрнең җирле администрацияләре башлыклары (башкарма комитетлары җитәкчеләре) муниципаль хокукый актларны чыгарганда хокук куллану практикасында бозулар рөхсәт ителмәвен күрсәтте.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 73 статьясы буенча Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан ачыкланган Татарстан Республикасындагы муниципаль берәмлекнең җирле администрациясе башлыгы (башкарма комитеты җитәкчесе) тарафыннан чыгарыла торган хокукый актларның формасына карата закон белән билгеләнгән таләбен үтәүнең конституциячел-хокукый мәгънәсе Татарстан Республикасындагы барлык муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары өчен мәҗбүри.

Шул ук вакытта, эш материалларыннан күренгәнчә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы Уставның дәгъвалана торган нормасын федераль һәм республика законнары таләпләренә тәңгәл китерү һәм Татарстан Республикасы Конституция судының күрсәтелгән хокукый позициясен үтәү буенча тиешле гамәлләр башкармаган.

Моңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Уставының 74 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты ул Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе чыгара торган норматив хокукый актларның тиешле булмаган формасын билгеләгән дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституциясенең 24 статьясы (икенче өлеш) нигезләмәләренә туры килми, алар буенча җирле үзидарә органнары Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә тиеш. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советына, Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып һәм Татарстан Республикасы Конституция судының шул исәптән әлеге Карарда да бәян ителгән хокукый позицияләрен исәпкә алып, Уставка «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы таләпләренә нигезләнгән тиешле үзгәрешләр кертергә кирәк.

4.2. Уставның 79 статьясындагы 9 өлешенең өченче абзацы нигезләмәләренең анда норматив хокукый актны рәсми рәвештә бастырып чыгару көнен аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге тиешле ресурсларда урнаштыру юлы белән бастырып чыгарган очракта күрсәтү

таләбе билгеләнмәгән дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килмәве турындагы мөрәҗәгать итүчеләрнең позициясенә килгәндә, Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәгене билгеләп үтә.

Уставның 79 статьясындагы 3 өлеше нигезендә кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагыла торган муниципаль норматив хокукый актлар аларны рәсми рәвештә бастырып чыгарганнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керәләр. Китерелгән норматив нигезләмә дәгъвалана торган норма белән, шулай ук Уставның муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибен җайга сала торган башка нигезләмәләре белән аерылгысыз хокукый берлектә, бу кабул ителгән муниципаль хокукый актны бастырып чыгару көнен күрсәтү тиешлеген күздә тота, ул аның шуннан соң үз көченә керүенең төп шарты булып тора. Шул ук вакытта андый таләпнең турыдан-туры Уставның 79 статьясындагы 9 өлешенең өченче абзацында булмавы үзеннән-үзе норматив хокукый актны бастырып чыгару көнен күрсәтү мәҗбүри булган гомумбилгеләнгән тәртипне үтәмәскә мөмкинлек бирми. Моны Татарстан Республикасы Питрәч мунципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителә торган муниципаль хокукый актларны районның рәсми сайтында урнаштыру практикасы да раслый, аны анализлау әлеге таләпнең тиешле тәртиптә үтәлгәнен һәм башкарылганын күрсәтте.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2015 елның 21 маендагы 14/235 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Уставының 79 статьясындагы 9 өлешенең өченче абзацының дәгъвалана торган нигезләмәләре кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын, шул исәптән мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын юкка чыгармыйлар, киметмиләр һәм башкача бозмыйлар.

Уставның 79 статьясындагы 9 өлешенең өченче абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип тану Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителә торган муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) тәртибен хокукый җайга салуны камилләштерүгә комачауламый. Шуңа бәйле рәвештә Уставка басма массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыга (халыкка җиткерелә) торган муниципаль хокукый актлар мөнәсәбәтендә инде билгеләнгәнгә (Уставның 79 статьясындагы 9 өлешенең дүртенче абзацы) тиңдәш булган кабул ителгән муниципаль хокукый актны аны районның рәсми сайтында һәм Порталда урнаштырганда бастырып чыгару көнен күрсәтү мәҗбүрилеген регламентлаштыра торган нигезләмәләр кертү муниципаль хокукый актларны басма массакүләм мәгълүмат чараларында да, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге тиешле рәсми ресурсларда да бастырып чыгарганда (халыкка җиткергәндә) бертөрле алым кулланылуга ярдәм итәр иде.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты кабул иткән мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан дәгъвалана торган норматив хокукый актлар тәрбия, мәгариф буенча гомуми мәсьәләләргә кагыла, алар Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлеш, «е» пункты) нигезендә Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагында. Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителә торган законнары һәм башка норматив хокукый актлары чыгарыла; Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары федераль законнарга каршы килә алмый (Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясы, 2 һәм 5 өлешләр).

Белем алуга хокукны тормышка ашыру, мәгариф өлкәсендә кеше хокуклары һәм ирекләренең дәүләт гарантияләрен тәэмин итү һәм белем алуга хокукны тормышка ашыру өчен шартлар булдыру белән бәйле барлыкка килә торган иҗтимагый мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

Аталган Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты нигезендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарының мәгариф өлкәсендәге вәкаләтләренә Россия Федерациясе субъектлары белем бирү оешмаларын булдыру, үзгәртеп оештыру, бетерү, Россия Федерациясе субъектлары белем бирү оешмаларын гамәлгә куючылар функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкару керә. Муниципаль белем бирү оешмалары мөнәсәбәтендә әлеге Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешенең 4 пункты буенча мондый вәкаләтләргә җирле үзидарә органнары да ия.

Әлеге Федераль законның 22 статьясындагы 10 өлеше нигезендә белем бирү оешмасы, мәгариф турындагы законнар белән каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, граждан законнарында билгеләнгән тәртиптә үзгәртеп оештырыла яки бетерелә. Андый үзенчәлекләр исәбенә федераль закон чыгаручы белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү тиешлеген кертә. Күрсәтелгән Федераль законның 22 статьясындагы 14 өлеше нигезендә Россия Федерациясе субъекты карамагындагы белем бирү оешмалары һәм муниципаль белем бирү оешмалары мөнәсәбәтендә аларны үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне (бу бәяләүнең (әлеге белем бирү оешмалары типлары буенча) критерийларын кертеп) үткәрү тәртибен, шулай ук мондый карарның нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссия төзү һәм аның тарафыннан бәяләмәләр әзерләү тәртибен билгеләү буенча вәкаләтләр Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы карамагына кертелгән.

Татарстан Республикасында дәүләт хакимиятенең шундый

вәкаләтле органы булып «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясындагы 5 өлешенә күрә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тора, ул дәгъвалана торган Тәртипне раслаган һәм Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләренә тиешле норматив хокукый актларны кабул итәргә тәкъдим иткән. Әлеге күрсәтмәне үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты 2016 елның 8 июнендәге 881 номерлы карары белән дәгъвалана торган Комиссия турында нигезләмәне раслаган һәм анда Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру, бетерү, реконструкцияләү, модернизацияләү, аның статусын һәм билгеләнешен үзгәртү хакында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссия төзү һәм аның эшчәнлеген оештыру процедурасын билгеләгән.

Шуның белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты федераль һәм республика законнары нигезендә үзләренә караган вәкаләтләрне законлы рәвештә гамәлгә ашырганнар.

5.1. Татарстан Республикасы Конституциясе Татарстан Республикасын социаль дәүләт дип игълан итеп (13 статья), дәүләт яисә муниципаль мәгариф учреждениеләрендә төп гомуми белем алу мөмкинлеген һәм аның түләүсезлеген гарантияли (56 статья, икенче өлеш). Тиңдәш нигезләмәләр Россия Федерациясе Конституциясенең 43 статьясында (2 өлеш) беркетелгән.

Китерелгән конституциячел күрсәтмәләргә Мәгариф өлкәсендәге дискриминациягә каршы көрәш турында конвенция (ЮНЕСКО Генераль конференциясе тарафыннан 1960 елның 14 декабрендә кабул ителгән) нигезләмәләре һәм Икътисади, социаль һәм мәдәни хокуклар турында халыкара пактның 13 статьясы туры килеп тора, алар белем алу мөмкинлеген бөтен кешеләр өчен тигез хокук һәм мөмкинлек итеп билгелиләр, бу исә икътисади мөмкинлекне генә (аерым алганда, түләүсез башлангыч белем алуны булдыру) күзалламыйча, физик мөмкинлекне дә күздә тота, соңгысы итеп аталган актларда белем алуга имин физик мөмкинлек я ярашлы географик ераклыкта урнашкан уку йортына йөрү, я заманча технологияләрдән файдалану мөмкинлегенә ия булу дип аңлашыла.

Россия Федерациясе Конституция Суды күрсәткәнчә, белем алуга хокукны һәм аның бер элементы буларак — дәүләт яки муниципаль белем бирү учреждениеләрендә түләүсез мәктәпкәчә белем алу мөмкинлегенә хокукны беркетеп, Россия Федерациясе Конституциясе турыдан-туры әлеге хокукны гарантияләү системасын да билгели, ул дәүләт һәм муниципаль берәмлекләр — яшәү урынына бәйсез рәвештә мәктәпкәчә белем алу мөмкинлеге булу конституциячел таләбеннән чыгып — булган мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен җитәрлек санда сакларга тиешләр дип шул исәптән күздә тота (2006 елның 15 маендагы 5-П номерлы Карар).

Әлеге хокукый позиция тулысынча гражданнарның төп гомуми белем алуларын тәэмин итү мәсьәләләренә карата да кулланылырга мөмкин.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законда белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру яки бетерү тәртибен, шулай ук муниципаль белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру яки бетерү сәбәпле гражданнарның белем алуга хокукларын яклауны тәэмин итә торган шартларны билгеләп, федераль закон чыгаручы Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органы яки җирле үзидарә органы тарафыннан дәүләт һәм (яки) муниципаль белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү мондый карарның нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссиянең уңай бәяләмәсе нигезендә рөхсәт ителә дип күздә тоткан (22 статьяның 11 өлеше). Тиңдәш таләп «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 13 статьясындагы 3 өлешендә дә билгеләнгән.

Федераль һәм республика законнарының күрсәтелгән нигезләмәләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 5 февралендәге 63 номерлы карары белән расланган дәгъвалана торган Тәртипнең Татарстан Республикасы карамагындагы белем бирү оешмасын, муниципаль белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү процедурасын да, шулай ук мондый карарның нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссия төзү һәм аның тарафыннан бәяләмәләр әзерләү процедурасын да билгели торган нормаларында үсеш алган.

Тәртипнең 1.2 һәм 1.5 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләренә күрә муниципаль гомуми белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул иткәндә муниципаль белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссия (алга таба — комиссия) тарафыннан мондый карарның нәтиҗәләрен бәяләү үткәрелә, аның максаты булып республикада тулаем һәм (яки) билгеле бер территориядә үзгәртеп оештыру яки бетерү процедурасыннан соң белем бирү системасы торышын һәм халыкның белем бирү хезмәтләренә ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен моннан соң барлыкка килгән шартларны билгеләү тора.

Тәртипнең дәгъвалана торган 1.3 пункты нигезендә муниципаль гомуми белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү критерие — түбәндәгеләрне исәпкә алып, бу муниципаль берәмлек территориясендә гражданнарның федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә тиешле дәрәҗәдәге белем алуы өчен шартларны саклау, шулай ук билгеле бер территорияне үстерүнең башка шартларын саклау:

балалар демография вәзгыятен (белем бирү оешмасына укырга керәчәк балалар саны, сыйныфлар (төркемнәр) саны үзгәрү турында фаразлар);

бу муниципаль берәмлектә гражданнарны тиешле белем бирү программаларын тормышка ашыру буенча белем бирү

эшчәнлеген гамәлгә ашыручы башка белем бирү оешмаларына кабул итү мөмкинлеге булуны;

бу муниципаль берәмлектә тиешле белем бирү программаларын тормышка ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы башка белем бирү оешмаларының территориаль файдалана алу мөмкинлеген (шул исәптән укучыларны белем бирү оешмаларына кадәр транспорт белән озата баруны оештыру мөмкинлеген һәм (яки) аларның анда тәүлек буе булуын исәпкә алып);

социаль-җитештерү шартларын (белем бирү оешмасы хезмәт күрсәткән территориядә эшләп торучы сәнәгать яки авыл хуҗалыгы предприятиеләре булу, аларның перспективалары, бу территориядәге эшкә сәләтле халык саны динамикасы), шулай ук мондый карарны кабул иткәннән соң бу территориядән халыкның (яшь гаиләләрнең) күчеп китү мөмкинлеге турындагы фаразларны;

муниципаль белем бирү оешмасының матди-техник базасын (биналар тасвирнамәсе (бинаның төзелү елы, тибы һ.б.), төзелмәләр һәм аларның мәйданнары санитар-техник нормаларга туры килү; җир кишәрлекләре территориясен төзекләндерү дәрәҗәсе; җиһазлар, җайланмалар булу һәм аларның торышы, кабинетларны (залларны) җиһазлар һәм җайланмалар белән җиһазландыру, шулай ук билгеләнгән үзгәрешләрне кертүгә бәйле рәвештә, мөлкәттән файдалану перспективалары).

Тәртипнең 1.3 пункты белән билгеләнгән критерийлар үзенең хокукый табигате буенча уйланылган үзгәртеп оештыру тиешле яки киресенчә тиешсез булачагын билгели торган җитәрлек нигезләрне ачыклауга юнәлгән һәм тиешле карарны кабул иткәндә билгеләүче әһәмияткә ия киң мәсьәләләр спектрын колачлый. Тәртипнең 2.10 һәм 2.14 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләренең сүзгә-сүз әчтәлегеннән аңлашылганча, әлеге критерийлар, аларны анализлау һәм мәҗбүри исәпкә алу белем бирү оешмасын гамәлгә куючы тарафыннан аны үзгәртеп оештыру яки бетерү кирәклеге турында тәкъдим әзерләү өчен дә, шулай ук мондый карар кабул итүнең мөмкин булган нәтиҗәләрен комиссия бәяләү өчен дә бердәнбер хокукый шарт булып торалар. Шул ук вакытта Тәртипнең 2.19 пункты нигезендә белем бирү оешмасын гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы органга җибәрелә торган комиссия бәяләмәсендә бу комиссия тарафыннан Тәртипнең 1.3 пункты белән билгеләнгән һәр критерий буенча белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләренең уңай я тискәре бәяләмәсенә нигезләмә күрсәтелгән булырга тиеш.

Шуның белән мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан дәгъвалана торган нормалар үзләренең мәгънәсе һәм эчтәлеге буенча муниципаль белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру турында карар кабул итү өчен әһәмияткә ия булган бөтен шартларны исәпкә алып, мондый карарны кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү һәм тиешле бәяләмәне әзерләү өчен кирәкле таләпләр һәм гамәлләр

эзлеклелеге булып торалар. Башкача әйткәндә, белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү беренче чиратта һәркемнең белем алуга гарантияләнгән хокукын тәэмин итү буенча конституциячел әһәмияткә ия максатны күздә тота һәм шуңа бәйле рәвештә, белем бирү процессының җайлы һәм уңайлы шартларын саклау, шулай ук дәүләт һәм иҗтимагый мәнфәгатьләр балансы нигезендә гражданнар ихтыяҗларын комплекслы исәпкә алу кирәклегеннән чыгып, югарыда күрсәтелгән һәр критерийны тулы һәм объектив анализлауга нигезләнә.

Шулай итеп, Тәртипнең 1.3, 2.14 һәм 2.19 пунктлары системалы берлектә торалар, үзләренең максатчан билгеләнеше буенча муниципаль белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү процедурасын җайга салуга юнәлгән, хокук кулланучылар өчен мондый бәяләүнең тулы критерийларын билгелиләр, мәҗбүри характерга ия, хокук куллану практикасында аларны башкача аңлатуга юл куймыйлар һәм үзләреннән-үзе кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын, шул исәптән мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын юкка чыгармыйлар, киметмиләр һәм башкача бозмыйлар һәм, димәк, Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 38 (беренче һәм өченче өлешләр), 56 (беренче һәм икенче өлешләр) статьяларына каршы килмиләр.

5.2. Питрәч муниципаль районы белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру, бетерү, реконструкцияләү, модернизацияләү, аның статусын һәм билгеләнешен үзгәртү хакында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссияне (алга таба — Комиссия) төзү һәм аның эшчәнлеген оештыру процедурасы, шулай ук районның җирле үзидарә органы тарафыннан шундый карар кабул итү тәртибе дәгъвалана торган Комиссия турында нигезләмә нормалары белән җайга салынган.

Комиссия турында нигезләмәнең 8 һәм 10 пунктларының үзара бәйле нормалары буенча Комиссия гомуми белем бирү оешмалары тибына караган белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне әлеге Нигезләмәнең 8 пунктындагы 8.1 пунктчасында билгеләнгән критерийлар нигезендә үткәрә.

Дәгъвалана торган норманы сүзгә-сүз эчтәлегеннән чыгып анализлау шуны күрсәтә: анда беркетелгән критерийлар исемлеге зуррак юридик көчкә ия булган норматив хокукый актта, атап әйткәндә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 5 февралендәге 63 номерлы карары белән раслангган Тәртипнең 1.3 пунктында билгеләнгән тиңдәш критерийлар исемлеге белән чагыштырганда шактый кыскарган. Шулай, Комиссия турында нигезләмәнең 8 пунктындагы 8.1 пунктчасында социаль-җитештерү шартларын, андый карарны кабул иткәннән соң бу территориядән халыкның (яшь гаиләләрнең) күчеп китү мөмкинлеге турындагы фаразларны, шулай ук муниципаль белем бирү оешмасының матди-техник базасын исәпкә алу тиешле-

ген күздә тота торган мәгънә буенча да, эчтәлек буенча да тиңдәш булган бәяләү критерийлары чагылыш тапмаган.

Комиссия турында нигезләмәнең 19 пункты буенча гомуми белем бирү оешмалары тибына караган белем бирү оешмасы мөнәсәбәтендә Комиссия карары Комиссия турында нигезләмәнең 8 пунктындагы 8.1 пунктчасы белән билгеләнгән критерийлар нигезендә кабул ителә. Әлеге норманың сүзгә-сүз эчтәлегеннән аңлашылганча, ул императив характерга ия һәм Комиссиягә үзенең карарларын кабул иткәндә дәгъвалана торган нормада беркетелгәннәрдән үзгә нинди дә булса башка критерийларга таяну мөмкинлеген күздә тотмый. Шул ук вакытта Комиссия турында нигезләмәнең 8 пунктындагы 8.1 пунктчасында зуррак юридик көчкә ия булган акт белән билгеләнгән критерийларның булмавы норматив хокукый актлар иерархиясен бозып кына калмыйча, Комиссия тарафыннан нигезсез һәм объектив булмаган карар кабул ителүгә дә китерергә мөмкин. Үткәрелә торган бәяләү критерийларында булган аермалыклар Комиссия бәяләмәләре эчтәлегенең белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру яки бетерүнең реаль кирәклеге һәм мөмкинлеге белән туры килмәвен генә түгел, ә бер белем бирү оешмасы мөнәсәбәтендә берьюлы төрле норматив хокукый актлар нигезендә үткәрелергә мөмкин булган бәяләү нәтиҗәләренең бер-берсенә туры килмәвен дә, нәтиҗәнең икесе дә карала торган җайга салу кысаларында ышанычлы дип санала алган хәлдә, котылгысыз итәләр. Андый каршылыклар аерым муниципаль район үсеше үзенчәлекләре күзлегеннән дә акланырга мөмкин түгел, чөнки белем алуга хокук аның гражданнарның яшәү урынына бәйсез рәвештә мөмкин булуын күздә тота һәм юридик тигезлек конституциячел принцибы нигезендә гарантияләнә.

Татарстан Республикасы Конституция суды шундый нәтиҗәгә килә: дәгъвалана торган хокукый җайга салу Комиссиягә үз эшендә тулы булмаган мәгълүматларга таянырга боера, чөнки аның белән билгеләнгән критерийлар исемлеге җирле үзидарә органы тарафыннан муниципаль белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләренең тулы күләмен чагылдыра алмый, һәм шуның белән Комиссия бәяләмәсен дә, шуннан соң белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карарны да кабул итүнең нигезле һәм законлы булуын шик астына куя.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 8 июнендәге 881 номерлы карары белән расланган Питрәч муниципаль районы белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру, бетерү, реконструкцияләү, модернизацияләү, аның статусын һәм билгеләнешен үзгәртү хакында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссия турында нигезләмәнең 8 пунктындагы 8.1 пунктчасы Татарстан Республикасы Конституциясенә, аның 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 56 (беренче һәм икенче өлешләр) статьяларына туры килми.

5.3. 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1

өлешенең 11 пункты нигезендә төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә караган белем бирү процессын финанс яктан тәэмин итү буенча вәкаләтләрдән тыш, муниципаль районның җирле әһәмияттәге мәсьәләсе булып тора.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 22 статьясындагы 12 өлеше, шулай ук «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 13 статьясындагы 4 өлеше әчтәлегеннән аңлашылганча, җирле үзидарә органы тарафыннан авыл җирлегендә урнашкан муниципаль гомуми белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карарны бу авыл җирлеге халкының фикерен исәпкә алмыйча кабул итү рөхсәт ителми.

131-ФЗ номерлы Федераль закон 5 бүлегендә халыкның җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыру һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашу формаларын билгеләп һәм нинди мәсьәләләр җирле референдумда (22 статья), гражданнар җыенында (25, 25.1 статьялар), гражданнар җыелышында (29 статья) чишелергә тиешле булуын ачыклап, 31 статьясындагы 1 өлешендә турыдан-туры шуны күрсәтә: халык фикере аны җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары карарлар кабул иткәндә исәпкә алу максатында муниципаль берәмлекнең бөтен территориясендә яки аның бер өлешендә үткәрелә торган гражданнардан сорашып белешү юлы белән ачыклана. Федераль закон чыгаручы аталган статьяда шулай ук җирле үзидарә органының гражданнардан сорашып белешү үткәрүне билгеләү һәм уздыру тәртибен Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә муниципаль берәмлек уставы һәм (яисә) муниципаль берәмлек вәкиллекле органының норматив хокукый актлары белән билгеләү бурычын күздә тоткан (4 өлеш). Тиңдәш рәвештә әлеге мәсьәлә «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 5.1 өлеше нигезләмәләре белән җайга салынган.

Шулай итеп, китерелгән федераль һәм республика законнары нигезләмәләре мәгънәсеннән чыгып, җирле үзидарә органнары карарлар кабул иткәндә тиешле муниципаль берәмлектә яшәүче гражданнарның фикерен ачыклау һәм исәпкә алуның законда билгеләнгән формасы булып сорашып белешү тора. Шул ук вакытта Комиссия турында нигезләмәнең 11 пунктындагы дәгъвалана торган 5 пунктчасы әчтәлегеннән аңлашылганча, ул билгеләгән хокукый җайга салу гражданнарның муниципаль белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында мәсьәлә хәл ителгәндә катнашуының бүтән формасын — гражданнар җыелышын күздә тота.

Гражданнардан сорашып белешүне һәм гражданнарның җыелышын үткәрү максатларын һәм тәртибен җайга сала торган югарыда күрсәтелгән законнар нормаларын һәм Татарстан Рес-

публикасы Питрәч мунципаль районы Уставы нигезләмәләрен анализлау халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда турыдан-туры катнашуының әлеге формаларының үзләренең хокукый табигате һәм юридик нәтиҗәләр буенча төрле булуларын күрсәтә.

Гражданнардан сорашып белешү, Уставның 23 статьясы нигезендә, җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары карарлар кабул иткәндә халык фикерен ачыклау һәм исәпкә алу өчен Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының бөтен территориясендә яки территориясенең бер өлешендә үткәрелә. Шул ук вакытта Уставның шушы ук статьясы буенча җирле үзидарә органнары тиешле карарлар кабул иткәндә сорашып белешү нәтиҗәләре мәҗбүри исәпкә алынырга һәм аны үткәргәннән соң бер ай эчендә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш, алар белән әлеге районның һәр яшәүчесе танышырга хокуклы. Уставның күрсәтелгән нормалары Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2009 елның 29 октябрендәге 39 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясендә гражданнардан сорашып белешүне билгеләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәдә үсеш алган һәм конкретлаштырылган, аның буенча җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары сорашып белешү нәтиҗәләренә каршы килә торган карарлар кабул иткән очракта күрсәтелгән органнар тиешле карарны кабул иткәннән соң 10 көн эчендә андый карар кабул итү сәбәпләрен тиешле мәгълүматны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) юлы белән халыкка хәбәр итәргә тиеш (15.3 пункт).

Гражданнар җыелышына килгәндә, аның максатчан билгеләнеше булып, Уставның 21 статьясында күрсәтелгәнчә, җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча фикер алышу, халыкка Питрәч муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү, шулай ук әлеге район территориясенең бер өлешендә территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру тора. Күрсәтелгән статья нигезендә гражданнар җыелышы районның җирле үзидарә органнарына һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларына мөрәҗәгатьләр кабул итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары белән үзара мөнәсәбәтләрдә гражданнар җыелышы вәкилләре булырга вәкаләтләнгән затларны сайларга мөмкин (8 өлеш); гражданнар җыелышы кабул иткән мөрәҗәгатьләр әлеге районның компетенцияләренә мөрәҗәгатьләрдәге мәсьәләләрне хәл итү кертелгән җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан, язма җавап җибәрелеп, мәҗбүри каралырга тиеш (10 өлеш); гражданнар җыелышы нәтиҗәләре рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш (12 өлеш).

Шулай итеп, дәгъвалана торган норма белән билгеләнгән гражданнар фикерен алардан сорашып белешү рәвешендә түгел, ә ха-

лык җыелышы карары рәвешендә ачыклау һәм исәпкә алу формасы гражданнарга белем бирү оешмасын уйланылган үзгәртеп оештыруга карата фикерләрен бәян итү һәм андый фикерне мәҗбүри исәпкә алу хокукын гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми, шулай ук гражданнарга җирле үзидарә органнары тарафыннан сорашып белешү нәтиҗәләренә туры килмәгән карар кабул итү сәбәпләре турында нигезләнгән җавап алуга хокукны гарантияләми.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституция суды Комиссия турында нигезләмәнең 11 пунктындагы 5 пунктчасы ул муниципаль белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул иткәндә халык фикерен ачыклау һәм исәпкә алуның тиешле булмаган формасын билгеләгән дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституциясенең 24 (икенче өлеш), 48 (икенче өлеш), 56 (беренче һәм икенче өлешләр) статьяларына туры килми дигән нәтиҗәгә килә.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6, 63 статьяларына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67, 68, 69, 71, 73 һәм 104 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2015 елның 21 маендагы 14/235 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Уставын һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 8 июнендәге 881 номерлы карарын аларны рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибе буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 30 маендагы 762 номерлы карарын һәм аның белән расланган Питрәч муниципаль районы белем бирү оешмаларын булдыру, үзгәртеп оештыру һәм бетерү тәртибе турында нигезләмәне тулысынча, алар билгеләнгән тәртиптә гомуми танышу өчен рәсми рәвештә басылып чыкмаганга күрә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, аның 24 статьясына (өченче өлеш), шулай ук, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты гражданнарның аларның хокукларына, ирекләренә һәм законлы мәнфәгатьләренә кагыла торган җирле үзидарә органнары кабул иткән карарлар белән танышу хокукларын тәэмин итү буенча бурычын үтәмәгәнгә күрә, аның 48 статьясына (икенче өлеш) туры килми дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 30 маендагы 762 номерлы карары белән расланган Питрәч муниципаль районы белем бирү оешмаларын булдыру, үзгәртеп оештыру һәм бетерү тәртибе турында нигезләмәнең 3.4 пунктындагы 3.4.1 пунктчасы һәм 3 бүлегенең

конституциячеллеген тикшерү өлешендә эш башкаруны туктатырга.

4. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2015 елның 21 маендагы 14/235 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Уставының 74 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенең 24 статьясына (икенче өлеш) туры килми дип танырга.

5. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2015 елның 21 маендагы 14/235 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Уставының 79 статьясындагы 9 өлешенең өченче абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 5 февралендәге 63 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы карамагындагы белем бирү оешмасын, муниципаль белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне (бу бәяләүнең (әлеге белем бирү оешмалары типлары буенча) критерийларын кертеп) үткәрү тәртибенең, шул исәптән мондый карарның нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссия төзү һәм аның тарафыннан бәяләмәләр әзерләү тәртибенең 1.3, 2.14 һәм 2.19 пунктларын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

7. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 8 июнендәге 881 номерлы карары белән расланган Питрәч муниципаль районы белем бирү оешмасын үзгәртеп оештыру, бетерү, реконструкцияләү, модернизацияләү, аның статусын һәм билгеләнешен үзгәртү хакында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссия турында нигезләмәнең 8 пунктындагы 8.1 пунктчасын һәм 11 пунктындагы 5 пунктчасын Татарстан Республикасы Конституциясенә, аның 24 (икенче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 48 (икенче өлеш), 56 (беренче һәм икенче өлешләр) статьяларына туры килми дип танырга.

8. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советына һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетына — Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып һәм Татарстан Республикасы Конституция судының әлеге Карарда бәян ителгән шул таләпләргә нигезләнгән хокукый позицияләрен исәпкә алып — Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясендә гамәлдә булган хокукый җайга салуга әлеге Карардан килеп чыга торган тиешле үзгәрешләр кертергә кирәк.

Тиешле үзгәрешләр кертелгәнче, хокук кулланучылар Татарстан Республикасы Конституция судының бу Карарда бәян ителгән хокукый позицияләренә таянырга тиеш.

9. Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танылган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 30 маендагы 762 номерлы

карарына һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 8 июнендәге 881 номерлы карарының аерым нигезләмәләренә таянган хокук куллану карарлары, әлеге Карарда ясалган нәтиҗәләрне исәпкә алып, билгеләнгән тәртиптә, моның өчен башка киртәләр булмаса, яңадан каралырга тиеш.

10. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

11. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясы буенча бу Карар «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 73-П

Татарстан Республикасы
Конституция суды

ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

26 января
2017 года
город Казань

об отказе в принятии к рассмотрению ходатайства гражданки М.Н. Павловой об официальном разъяснении постановления Конституционного суда Республики Татарстан от 21 октября 2016 года № 70-П

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи А.А. Хамматовой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение обращения гражданки М.Н. Павловой,

установил:

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка М.Н. Павлова с ходатайством об официальном разъяснении постановления Конституционного суда Республики Татарстан от 21 октября 2016 года № 70-П по делу о проверке конституционности абзаца шестого приложения № 2 к инструкции «О порядке оформления документов при передаче жилых помещений в собственность граждан (приватизации) на территории города Казани», утвержденной постановлением руководителя Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 8 ноября 2006 года № 2346, и абзаца двенадцатого пункта 2.5 графы «Содержание требования к стандарту предоставления муниципальной услуги» раздела II Административного регламента предоставления муниципальной услуги по оформлению договоров на передачу жилых помещений в собственность граждан (приватизацию), утвержденного постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 28 июня 2012 года № 4310.

Постановлением Конституционного суда Республики Татарстан от 21 октября 2016 года № 70-П обжалуемые нормы были признаны не противоречащими Конституции Республики Татарстан в части установления требования о том, что для оформления заявления на приватизацию жилого помещения, из которого были выписаны несовершеннолетние члены семьи, необходимо иметь разрешение органов опеки и попечительства.

Заявительница отмечает, что правоприменительные органы придают рассматриваемым нормам неверное истолкование и требуют представления разрешения органов опеки и попечительства вне зависимости от того, являются выписанные из жилого помещения несовершеннолетние членами семьи нанимателя или таковыми не являются. Между тем гражданка М.Н. Павлова считает, что установленное оспоренными нормами требование о представлении указанного разрешения распространяется лишь на тех выписанных из жилого помещения несовершеннолетних,

которые являются членами семьи нанимателя на момент обращения заявителя в уполномоченный орган для оформления приватизации. При этом она подчеркивает, что к членам семьи нанимателя в силу части 1 статьи 69 Жилищного кодекса Российской Федерации относятся проживающие совместно с ним его супруг, а также дети и родители данного нанимателя, а также другие родственники, если они вселены нанимателем в качестве членов его семьи и ведут с ним общее хозяйство.

В этой связи заявительница просит Конституционный суд Республики Татарстан разъяснить постановление Конституционного суда Республики Татарстан от 21 октября 2016 года № 70-П, а именно ответить на вопрос о том, признаны ли оспоренные нормы соответствующими Конституции Республики Татарстан в том числе постольку, поскольку установленное требование о представлении разрешения органов опеки и попечительства не распространяется на те случаи, когда выписанные из жилого помещения несовершеннолетние не являются членами семьи нанимателя.

2. В соответствии со статьей 77 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» официальное разъяснение решения Конституционного суда Республики Татарстан дается только самим Конституционным судом Республики Татарстан в своем заседании, в частности, по ходатайству лица, имеющего право на обращение в Конституционный суд Республики Татарстан. Как уже отмечал Конституционный суд Республики Татарстан, по смыслу данной нормы в ее взаимосвязи со статьей 68 указанного Закона Республики Татарстан официальное разъяснение не может быть простым воспроизведением решения суда и не должно выходить за пределы произведенной Конституционным судом Республики Татарстан проверки конституционности соответствующего нормативного правового акта (определения от 4 октября 2001 года № 5-О и от 14 декабря 2005 года № 11-О).

Конституционный Суд Российской Федерации также указывал, что ходатайство о даче официального разъяснения не может быть рассмотрено, если представленные в нем вопросы не требуют какого-либо дополнительного истолкования решения по существу или формулирования новых правовых позиций (определения от 20 апреля 2010 года № 593-О-Р, от 24 сентября 2013 года № 1270-О-Р, от 24 декабря 2013 года № 1928-О-Р).

Из содержания мотивировочной части постановления Конституционного суда Республики Татарстан от 21 октября 2016 года № 70-П следует, что, исходя из системного толкования оспариваемых норм, разрешение органов опеки и попечительства на приватизацию жилого помещения, из которого был выписан несовершеннолетний, может быть истребовано, только если приватизация жилого помещения осуществляется без участия несовершеннолетнего, который был ранее выписан из него, но не утратил право пользования им, в том числе когда законный представитель несовершеннолетнего, выписанного из приватизируемого жилого

помещения, но не утратившего право пользования этим жилым помещением, отказывается от реализации принадлежащего несовершеннолетнему права на приватизацию.

Рассматривая указанные нормы, Конституционный суд Республики Татарстан давал им оценку исходя из их места в системе действующего правового регулирования, а также из их буквального содержания и правового смысла, предусматривающего ограниченный круг несовершеннолетних, на которых распространяется действие оспариваемых норм, в том числе и с учетом того, что данное регулирование применимо в отношении выписанных несовершеннолетних, являющихся членами семьи нанимателя.

При этом статьей 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» установлено, что жалоба на нарушение конституционных прав и свобод законом Республики Татарстан или иным нормативным правовым актом допустима, если закон или иной нормативный правовой акт затрагивает конституционные права и свободы граждан; закон или иной нормативный правовой акт применен или подлежит применению в конкретном деле, рассмотрение которого завершено или начато в суде или ином органе. В этой связи приложенные к жалобе заявительницы копии документов могут рассматриваться как подтверждающие применение обжалуемых положений при разрешении конкретного дела заявителя.

Тем самым жалоба гражданки Т.А. Мироновой в части проверки конституционности пункта 3.3 Порядка, подпункта 1 пункта 54 Правил и отдельных положений подразделов 2.1 и 2.2 Регламента подведомственна Конституционному суду Республики Татарстан, исходит от надлежащего заявителя, соответствует критериям ее допустимости, установленным статьей 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», и не содержит каких-либо оснований для отказа в принятии к рассмотрению Конституционным судом Республики Татарстан.

4. Заявительница ходатайствует об освобождении ее от уплаты государственной пошлины, поскольку, как указано в жалобе, она является пенсионером и находится в тяжелом материальном положении.

Согласно статье 42 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» при обращении в Конституционный суд Республики Татарстан государственная пошлина взимается в порядке, установленном федеральным законодательством. В соответствии с пунктом 3 статьи 333.23 Налогового кодекса Российской Федерации конституционные (уставные) суды субъектов Российской Федерации, исходя из имущественного положения плательщика, вправе освободить его от уплаты государственной пошлины по делам, рассматриваемым указанными

судами, либо уменьшить ее размер, а также отсрочить (рассрочить) ее уплату в порядке, предусмотренном статьей 333.41 данного Кодекса.

В связи с этим Конституционный суд Республики Татарстан считает возможным удовлетворить ходатайство гражданки Т.А. Мироновой об освобождении ее от уплаты государственной пошлины.

На основании изложенного, руководствуясь частью пятой статьи 3, пунктом 1 части второй статьи 39, статьей 42, частями первой и второй статьи 45, пунктом 2 части первой статьи 46, частью первой статьи 51, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73, 100 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

определил:

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Т.А. Мироновой в части, касающейся проверки конституционности абзаца сорок первого части 1 статьи 28 Устава муниципального образования города Казани, утвержденного решением представительного органа муниципального образования города Казани от 17 декабря 2005 года № 3-5 (в редакции решения Казанской городской Думы от 25 декабря 2013 года № 16-28), и Правил благоустройства города Казани, утвержденных решением Казанской городской Думы от 18 октября 2006 года № 4-12, по форме их издания, поскольку в этой части она не отвечает требованиям Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», в соответствии с которыми жалоба признается допустимой.

2. Принять к рассмотрению жалобу гражданки Т.А. Мироновой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 3.3 Порядка формирования и использования бюджетных ассигнований муниципального дорожного фонда города Казани, утвержденного решением Казанской городской Думы от 29 ноября 2013 года № 2-27 «О муниципальном дорожном фонде города Казани»; подпунктом 1 пункта 54 Правил благоустройства города Казани, утвержденных решением Казанской городской Думы от 18 октября 2006 года № 4-12; отдельными положениями подразделов 2.1 и 2.2 Регламента проведения работ по содержанию автомобильных дорог общего пользования и элементов обустройства города Казани, утвержденного постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 13 августа 2014 года № 4735 «О порядке содержания автомобильных дорог общего пользования г. Казани».

3. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

4. Поскольку жалоба гражданки Т.А. Мироновой, жалобы граждан Л.И. Новоселовой и П.П. Гурова касаются одного и того же предмета, согласно статье 50 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» соединить дела по данным жалобам в одно производство.

5. Удовлетворить ходатайство гражданки Т.А. Мироновой в части освобождения ее от уплаты государственной пошлины.

6. О принятом решении уведомить стороны — гражданку Т.А. Миронову, Казанскую городскую Думу и Исполнительный комитет муниципального образования города Казани.

7. Назначить судьей-докладчиком по данному делу судью Конституционного суда Республики Татарстан Р.А. Сахиеву.

8. Дату рассмотрения настоящего дела Конституционным судом Республики Татарстан установить в порядке очередности слушания дел в заседаниях Конституционного суда Республики Татарстан.

9. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 6-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 статьясындагы 1 өлешенең кырык беренче абзацы; «Казан шәһәренең муниципаль юл фонды турында» Казан шәһәр Думасының 2013 елның 29 ноябрендәге 2-27 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибенең 3.3 пункты; Казан шәһәр Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренең 54 пунктындагы 1 пунктчасы; «Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын карап тоту тәртибе турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 13 августындагы 4735 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын һәм төзекләндерү элементларын карап тоту буенча эшләр башкару регламентының 2.1 һәм 2.2 бүлекчәләрендәге аерым нигезләмәләр белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Т.А. Миронова шикаяте буенча

2017 ел
6 февраль
Казан шәһәре

БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Т.А. Миронова шикаятен алдан өйрәнгән судья Р.Г. Сәхиева бәяләмәсен тыңлаганнан соң

а ч ы к л а д ы :

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Т.А. Миронова Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары (Казан шәһәр Думасының 2013 елның 25 декабрендәге 16-28 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының (алга таба шулай ук — Устав) 28 статьясындагы 1 өлешенең кырык беренче абзацы; «Казан шәһәренең муниципаль юл фонды турында» Казан шәһәр Думасының 2013 елның 29 ноябрендәге 2-27 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибенең (алга таба шулай ук — Тәртип) 3.3 пункты; Казан шәһәр Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренең (алга таба шулай ук — Кагыйдәләр) 54 пунктындагы 1 пунктчасы; «Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын карап

тоту тәртибе турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлегә Башкарма комитетының 2014 елның 13 августындагы 4735 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын һәм төзекләндерү элементларын карап тоту буенча эшләр башкару регламентының (алга таба шулай ук — Регламент) 2.1 һәм 2.2 бүлекчәләрендәге аерым нигезләмәләр белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Уставның 28 статьясындагы 1 өлешенең кырык беренче абзацында муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибен билгеләү Казан шәһәр Думасы вәкаләтләренә керә дип каралган.

Тәртипнең 3.3 пункты нигезендә чыгымнарның максатчан билгеләнеше буенча Казан шәһәренең муниципаль юл фондының расланган бюджет ассигнованиеләре күләме бүленеше алдагы финанс елына Казан шәһәре муниципаль берәмлегә Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

Кагыйдәләрнең 54 пунктындагы 1 пунктчасы юл территорияләрен карап тоту юлларны, тротуарларны, ясалма юл корылмаларын, квартал эчендәге машина юлларын төзекләндерүне үз эченә ала дип билгели.

Регламентның 2.1 һәм 2.2 бүлекчәләрендәге дәгъвалана торган нигезләмәләр Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы юлларын җәйге һәм кышкы җыештыруның төп технологик операцияләрен билгелиләр.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче яши торган Казан шәһәре, Академик Лаврентьев урамы адресы буенча урнашкан күпфатирлы йортның ишегалдындагы юлның һәм тротуарларның асфальт түшәмәсе йорт кулланылышка тапшырылганнан бирле (1983 елдан) ремонтланмаган һәм хәзерге вакытта бик нык таушалган һәм тулысынча җимерек хәлдә. Ишегалды территориясе, машина үтә торган юл өлеше һәм тротуарларның асфальт түшәмәсен ремонтлауны сорап, әлеге йортта яшәүчеләр Казан шәһәре муниципаль берәмлегә Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясенә, Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә, «“Уютный дом” идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә мөрәҗәгать иткән. Ләкин ишегалдындагы юл һәм тротуарларның асфальт түшәмәсен ремонтлау эшләре башкарылмаган.

Гражданка Т.А. Миронова фикеренчә, Тәртипнең 3.3 пункты, юл фондының бюджет ассигнованиеләрен бүлү вәкаләтен Казан шәһәре муниципаль берәмлегә Башкарма комитетына тапшырып, андый бүленешне башкарганда, Казан шәһәре муниципаль берәмлегә Уставының 28 статьясындагы 1 өлешенең кырык беренче абзацыннан күренгәнчә, җирле администрация таянырга тиешле һәм муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы дәрәҗәсендә билгеләнелергә тиешле бернинди дә критерийлар билгеләми. Башкасы, ул уйлаганча, әлеге фондтагы акчаларның ирекле бүленешенә һәм ремонтланырга тиешле юлларны һәм

квартал эчендәге машина юлларын объектив булмаган сайлауга китерә, бу аның конституциячел хокукларын боза.

Мөрәҗәгать итүче шулай ук билгеләгәнчә, Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренең 54 пунктындагы 1 пунктчасы юл территорияләрен карап тоту юлларны, тротуарларны, ясалма юл корылмаларын, квартал эчендәге машина юлларын төзекләндерүне үз эченә ала дип билгеләп, андый ремонт башкару тәртибен җайга салмый. Регламентның 2.1 һәм 2.2 бүлекчәләрендәге нигезләмәләр, аның фикеренчә, Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы юлларын җәйге һәм кышкы җыештыруның төп технологик операцияләренә юллар һәм тротуарлар ремонтлауны кертмиләр, бу Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләре нигезләмәсенә квартал эчендәге машина юлларын ремонтлауны юл территорияләрен карап тотуга кертми торган аңлатма бирә. Шул ук вакытта, гражданка Т.А. Миронова күрсәткәнчә, элегрәк гамәлдә булган Регламентта юлларны җәйге һәм кышкы җыештыруның төп технологик операцияләренә юллар һәм тротуарларга агымдагы ремонт ясау кертелгән булган.

Моннан тыш, мөрәҗәгать итүче билгеләгәнчә, Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләре Казан шәһәр Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган. Шуннан соң алар Казан шәһәр Думасының 2012 елның 7 июнендәге 4-14 номерлы карары белән расланган, 2013 елның 16 маендагы 17-22 номерлы, 2013 елның 25 декабрендәге 14-28 номерлы, 2014 елның 3 мартындагы 10-31 номерлы, 2014 елның 16 апрелендәге 15-32 номерлы карарлар белән үзгәрешләр 2012 елның 7 июнендәге 4-14 номерлы карар белән расланган Кагыйдәләргә кертелгән, ә 2014 елның 25 июлендәге 59-34 номерлы, 2014 елның 3 октябрендәге 27-36 номерлы, 2014 елның 29 октябрендәге 5-37 номерлы, 2015 елның 7 сентябрендәге 11-45 номерлы, 2015 елның 28 октябрендәге 19-2 номерлы карарлар белән үзгәрешләр Казан шәһәр Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләргә кертелгән. Шуңа бәйле рәвештә, аның фикеренчә, әлеге Кагыйдәләрнең раслануы белән аңлаешсызлык барлыкка килә. Мөрәҗәгать итүче санавынча, бу Казан шәһәр Думасы тарафыннан норматив хокукый актны бастырып чыгару формасын үтәмәү булып тора, бу исә аның конституциячел хокукларын шулай ук боза.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Т.А. Миронова Татарстан Республикасы Конституция судыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары (Казан шәһәр Думасының 2013 елның 25 декабрендәге 16-28 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 статьясындагы 1 өлешенең кырык беренче абзацын, «Казан шәһәренең муниципаль юл фонды турында» Казан шәһәр Думасының 2013 елның 29 ноябрендәге 2-27 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибенең 3.3 пунктын, Казан шәһәр Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы кара-

ры белән расланган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренең 54 пунктындагы 1 пунктчасын, «Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын карап тоту тәртибе турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 13 августындагы 4735 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын һәм төзекләндерү элементларын карап тоту буенча эшләр башкару регламентының 2.1 һәм 2.2 бүлекчәләрендәге Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы юлларын җәйге һәм кышкы җыештыруның төп технологик операцияләрен билгели торган аерым нигезләмәләрне Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче өлеш) һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

Мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Конституция судыннан шулай ук Казан шәһәр Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләрен норматив хокукый актны бастырып чыгару формасы буенча Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килә дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179.4 статьясындагы 5 пунктының бишенче абзацы нигезендә муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибе муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән билгеләнә.

Әлеге закон күрсәтмәләрен гамәлгә ашыру максатларында Уставның дәгъвалана торган нормасында Казан шәһәр Думасы — Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органы вәкаләтләренә шул исәптән Казан шәһәренең муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибен билгеләү турында карар кабул итү буенча вәкаләт кертелгән.

Шулай итеп, Уставның 28 статьясындагы 1 өлешенең мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган кырык беренче абзацында аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк. Шуңа күрә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый.

Казан шәһәр Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренең басылып чыгу формасы буенча конституциячел булмаулары турындагы мөрәҗәгать итүченең дәлилләренә килгәндә, шикаять әлеге өлешендә Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан шулай ук карауга алына алмый дип билгеләп үтәргә кирәк. «“Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләре турында” Казан шәһәр Думасы карарына үзгәрешләр керту хакында» Казан шәһәр Думасының 2015 елның 28 октябрендәге 19-2 номерлы карары белән гражданка Т.А. Миронова күрсәткән Казан

шәһәр Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләрен үзгәртә торган норматив хокукый актлар ул Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать иткәнгә кадәр үз көчен югалткан дип танылган, ә Кагыйдәләр исә яңа редакциядә бәян ителгән.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы икенче өлешенең мәгънәсе буенча Татарстан Республикасы Конституция суды конституциячел суд эшләрен башкарганда гамәлдәге норматив хокукый актларның конституциячеллеген тикшерә. Шикаять итүче Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итү алдыннан юкка чыгарылган яки үз көчен югалткан актларның конституциячеллеген тикшерү мөмкин түгел (Татарстан Республикасы Конституция судының 2010 елның 27 февралендәге 3-О номерлы билгеләмәсе).

Димәк, гражданка Т.А. Миронованың шикаяте Кагыйдәләрнең конституциячеллеген аларның басылып чыгу формасы буенча тикшерү өлешендә карала алмый.

3. Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы (дүртенче өлеш) һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды гражданнарның конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаятьләр буенча Татарстан Республикасы законының яисә аның аерым нигезләмәләренең, Татарстан Республикасы Президенты һәм Министрлар Кабинеты, шулай ук җирле үзидарә органнары норматив хокукый актларының конституциячеллеген тикшерә. Димәк, Тәртипнең 3.3 пункты, Кагыйдәләрнең 54 пунктындагы 1 пунктчасы һәм Регламентның 2.1 һәм 2.2 бүлекчәләрендәге аерым нигезләмәләр Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәү мәсьәләсенә тикшерелергә мөмкин.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 100 статьясындагы беренче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция судына конституциячел хокукларның һәм ирекләрнең бозылуына карата шикаять белән Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Президентының һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары белән хокуклары һәм ирекләре бозылган гражданнар һәм аларның берләшмәләре мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Шул ук вакытта «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 101 статьясы белән шул билгеләнгән: Татарстан Республикасы законы яисә башка норматив хокукый акт белән конституциячел хокуклар һәм ирекләрнең бозылуына шикаять бирү мөмкин була, әгәр закон яисә башка норматив хокукый акт гражданнарның конституциячел хокукларына һәм ирекләренә кагылса; закон яисә башка норматив хокукый акт, аны карау судта яисә башка органда

төгәлләнгән яки башланган конкрет эштә кулланылса яки кулланылырга тиеш булса. Шуңа бәйле рәвештә мөрәҗәгать итүченең шикаятенә кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләре дәгъвалана торган нигезләмәләрнең мөрәҗәгать итүченең конкрет эшен хәл иткәндә кулланылуын раслый торган итеп каралырга мөмкин.

Шуның белән гражданка Т.А. Миронова шикаяте Тәртипнең 3.3 пунктының, Кагыйдәләрнең 54 пунктындагы 1 пунктчасының һәм Регламентның 2.1 һәм 2.2 бүлекчәләрендәге аерым нигезләмәләрнең конституциячеллеген тикшерү өлешендә Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керә, тиешле мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 101 статьясында билгеләнгән шикаять бирү таләпләренә туры килә, һәм анда Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан карауга алудан баш тарту өчен нинди дә булса нигезләр юк.

4. Шикаятьтә күрсәтелгәнчә, мөрәҗәгать итүче пенсионер һәм авыр матди хәлдә булганга күрә, ул үзен дәүләт пошлинасын түләүдән азат итүне сорый.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 42 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать иткәндә дәүләт пошлинасы федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә алына. Россия Федерациясе Салым кодексының 333.23 статьясындагы 3 пункты нигезендә Россия Федерациясе субъектларының конституция (устав) судлары, түләүченең матди мөмкинлекләреннән чыгып, аны күрсәтелгән судлар карый торган эшләр буенча дәүләт пошлинасын түләүдән азат итәргә яки аның күләмен киметергә, шулай ук әлеге Кодексның 333.41 статьясында каралган тәртиптә аны түләүне кичектерергә (бүлгәләп түләтергә) хокуклы.

Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция суды гражданка Т.А. Миронованың үзен дәүләт пошлинасын түләүдән азат итү турындагы үтенечен канәгатьләндерергә мөмкин дип саный.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче өлешенә, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 42 статьясына, 45 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пунктына, 51 статьясындагы беренче өлешенә, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73, 100 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

билгеләде:

1. Гражданка Т.А. Миронова шикаятен Казан шәһәре муниципаль берәмлегә вәкиллекле органының 2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары (Казан шәһәр Думасының 2013 елның 25 декабрендәге 16-28 номерлы карары редакциясендә)

белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлегә Уставының 28 статьясындагы 1 өлешенең кырык беренче абзацының һәм басылып чыгу формасы буенча Казан шәһәр Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренең конституциячеллеген тикшерү өлешендә карауга алудан баш тартырга, чөнки әлеге өлештә ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының шикаять бирелергә мөмкин дигән таләпләренә җавап бирми.

2. «Казан шәһәренең муниципаль юл фонды турында» Казан шәһәр Думасының 2013 елның 29 ноябрендәге 2-27 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибенең 3.3 пункты; Казан шәһәр Думасының 2006 елның 18 октябрендәге 4-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренең 54 пунктындагы 1 пунктчасы; «Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын карап тоту тәртибе турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлегә Башкарма комитетының 2014 елның 13 августындагы 4735 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын һәм төзекләндерү элементларын карап тоту буенча эшләр башкару регламентының 2.1 һәм 2.2 бүлекчәләрендәге аерым нигезләмәләр белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Т.А. Миронова шикаятен карауга кабул итәргә.

3. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

4. Гражданка Т.А. Миронова шикаяте, гражданнар Л.И. Новоселова һәм П.П. Гуров шикаятьләре бер үк предметка кагылганга күрә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 50 статьясы нигезендә әлеге шикаятьләр буенча эшләрне бер башкаруга берләштерергә.

5. Гражданка Т.А. Миронованың үтенечен аны дәүләт пошлинасын түләүдән азат итү турындагы өлешендә канәгатьләндерергә.

6. Кабул ителгән карар турында якларга — гражданка Т.А. Мироновага, Казан шәһәр Думасына һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлегә Башкарма комитетына хәбәр итәргә.

7. Әлеге эш буенча докладчы судья итеп Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы Р.Г. Сәхиеваны билгеләргә.

8. Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан әлеге эшне карап тикшерү көнен Татарстан Республикасы Конституция суды утырышларында эшләрне тыңлау чираты тәртибендә билгеләргә.

9. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 6-О

Татарстан Республикасы Конституция суды

ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

9 февраля 2017 года город Казань

об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.С. Халиуллиной на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 2.1 Положения о порядке обмена жилых помещений муниципального жилищного фонда, утвержденного постановлением руководителя Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 3 июня 2008 года № 2565

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.А. Хамматовой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Р.А. Сахиевой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки Г.С. Халиуллиной,

установил:

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка Г.С. Халиуллина с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 2.1 Положения о порядке обмена жилых помещений муниципального жилищного фонда, утвержденного постановлением руководителя Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 3 июня 2008 года № 2565 «О порядке обмена жилых помещений муниципального жилищного фонда г. Казани» (далее также — Положение).

Оспариваемая заявительницей норма устанавливает, что наниматель жилого помещения муниципального жилищного фонда, желающий произвести обмен жилого помещения, представляет в уполномоченный орган заявление установленного образца (приложение № 1), заверяемое жилищно-эксплуатационной организацией по месту нахождения жилого помещения, подлежащего обмену, и справку жилищно-эксплуатационной организации по форме согласно приложению № 2.

Как следует из жалобы и приложенных к ней копий документов, гражданка Г.С. Халиуллина с 2010 года является нанимателем жилого помещения, расположенного по адресу улица Даурская города Казани, в котором она проживает с 1973 года, неся все расходы по его содержанию и оплачивая коммунальные и иные услуги. Ее сын в 1995 году вступил в брак с гражданкой, вставшей в 1999 году на регистрационный учет по указанному адресу. В 2009 году брак между ними был расторгнут. С 2007 года супруга сына в этой квартире не проживала, коммунальные услуги не оплачивала, но зарегистрировала в ней без согласия заявительницы своих детей и внучку. Заявительница указывает, что названные граждане не дают согласия на приватизацию данной квартиры, хотя фактическим местом их жительства является другая квартира в этом же жилом доме, а их регистрация в квартире гражданки Г.С. Халиуллиной является лишь формальной, тем самым это нарушает ее права как нанимателя жилого помещения. По ее утверждению, единственным реальным способом разрешения сложившейся

ситуации является принудительный обмен квартиры. Она также указывает, что Муниципальное унитарное предприятие города Казани «Дирекция муниципальных жилищных программ» на ее обращение по вопросу обмена занимаемого жилого помещения ответило, что в их картотеке подходящих вариантов обмена не имеется.

Гражданка Г.С. Халиуллина отмечает, что согласно форме заявления, установленной в приложении № 1 к оспариваемому Положению, необходимо указать жилую площадь, на которую заявитель просит произвести обмен своей жилой площади. В то же время обжалуемая норма не предусматривает право гражданина на подачу заявления о подборе иного жилого помещения для обмена при отсутствии у него варианта обмена жилого помещения, что, по ее мнению, противоречит Конституции Республики Татарстан.

На основании изложенного гражданка Г.С. Халиуллина просит Конституционный суд Республики Татарстан признать пункт 2.1 Положения о порядке обмена жилых помещений муниципального жилищного фонда, утвержденного постановлением руководителя Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 3 июня 2008 года № 2565, не соответствующим статьям 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 55 и 58 Конституции Республики Татарстан.

2. Обмен жилыми помещениями, предоставленными по договору социального найма, производится по правилам, установленным в статьях 72, 73 и 74 Жилищного кодекса Российской Федерации. Наниматель жилого помещения по договору социального найма с согласия в письменной форме наймодателя и проживающих совместно с ним членов его семьи, в том числе временно отсутствующих членов его семьи, вправе осуществить обмен занимаемого ими жилого помещения на жилое помещение, предоставленное по договору социального найма другому нанимателю (часть 1 статьи 72).

В указанном правовом регулировании при обмене жилого помещения, находящегося в собственности у государственного или муниципального жилищного фонда, предоставленного гражданину по договору социального найма, федеральный законодатель не предусматривает обязанности собственника такого помещения осуществлять подбор вариантов его обмена.

В целях реализации норм жилищного законодательства и совершенствования процедуры обмена жилых помещений муниципального жилищного фонда города Казани руководителем Исполнительного комитета муниципального образования города Казани утвержден рассматриваемый порядок, закрепляющий правила обмена жилых помещений муниципального жилищного фонда, занимаемых гражданами на основании договоров социального найма.

Осуществление органами местного самоуправления поиска вариантов обмена жилых помещений, находящихся в муниципальной собственности, при отсутствии у граждан вариантов обмена жилого помещения не входит в обязанности органов местного самоуправления, поскольку такое полномочие не предусмотрено действующим законодательством, а является только их дискрецией.

Таким образом, обжалуемый пункт 2.1 Положения о порядке обмена жилых помещений муниципального жилищного фонда не содержит неопределенности в вопросе о его соответствии Конституции Республики Татарстан и не может рассматриваться как нарушающий конституционные права и свободы человека и гражданина. В связи с этим согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба гражданки Г.С. Халиуллиной не является допустимой. Внесение же целесообразных, с точки зрения заявительницы, изменений в оспариваемое правовое регулирование не входит в компетенцию Конституционного суда Республики Татарстан, как она определена статьей 109 Конституции Республики Татарстан и статьей 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

На основании изложенного, руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

определил:

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.С. Халиуллиной на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 2.1 Положения о порядке обмена жилых помещений муниципального жилищного фонда, утвержденного постановлением руководителя Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 3 июня 2008 года № 2565 «О порядке обмена жилых помещений муниципального жилищного фонда г. Казани», поскольку она в соответствии с установленными требованиями Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не является допустимой, а разрешение поставленного заявительницей вопроса Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке Г.С. Халиуллиной и в Исполнительный комитет муниципального образования города Казани.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 7-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2008 елның 3 июнендәге 2565 номерлы карары белән расланган Муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру тәртибе турында нигезләмәнең 2.1 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.С. Хәлиуллина шикаятен карауга алудан баш тарту турында

2017 ел
9 февраль
Казан шәһәре

БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Г.С. Хәлиуллина шикаятен алдан өйрәнгән судья Р.Г. Сәхиева бәяләмәсен тыңлаганнан соң

а ч ы к л а д ы :

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Г.С. Хәлиуллина «Казан шәһәре муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру тәртибе турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2008 елның 3 июнендәге 2565 номерлы карары белән расланган Муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру тәртибе турында нигезләмәнең (алга таба шулай ук — Нигезләмә) 2.1 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган норма шуны билгели: муниципаль торак фондының торак урынын алмаштырырга теләк белдергән торак урын яллаучы кеше вәкаләтле органга тиешле үрнәктә язылган һәм алмаштырылырга тиешле торак урын урнашкан урындагы торак-эксплуатация оешмасы тарафыннан расланган гариза (1 нче кушымта) һәм 2 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча төзелгән торак-эксплуатация оешмасының белешмәсен тапшыра.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданка Г.С. Хәлиуллина 2010 елдан Казан шәһәренең Даурская урамында урнашкан торак урын яллаучысы булып тора, анда ул 1973 елдан бирле яши һәм коммуналь һәм башка хезмәтләр өчен түләп, торакны тоту буенча бөтен чыгымнарны каплап бара. Аның улы 1995 елда өйләнгән, ә хатыны күрсәтелгән адрес буенча 1999 елда теркәлгән булган. 2009 елда аларның никахлары таркалган. 2007 елдан улының хатыны әлеге фатирда тормаган, коммуналь хезмәтләр өчен түләмәгән, ләкин мөрәҗәгать итүченең рөхсәтеннән башка анда үз балаларын һәм оныгын теркәгән. Мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, аталган гражданнар әлеге фатирны хосусыйлаштыруга ризалык бирмиләр, гәрчә аларның яшәү урыны булып әлеге

торак йорттагы башка фатир тора, ә гражданка Г.С. Хәлиуллина фатирында теркәлүләре формаль гына, шуның белән бу аның торак урын яллаучысы буларак хокукларын боза. Аның раславы буенча, әлеге ситуацияне хәл итүнең бердәнбер реаль ысулы булып фатирны мәҗбүри алмаштыру тора. Ул шулай ук күрсәткәнчә, Казан шәһәренең «Муниципаль торак программалар дирекциясе» муниципаль унитар предприятиесе аның яшәгән торак урынны алмаштыру мәсьәләсе буенча мөрәҗәгатенә аларның картотекасында яраклы алмаштыру вариантлары юк дип җавап биргән.

Гражданка Г.С. Хәлиуллина билгеләгәнчә, дәгъвалана торган Нигезләмәгә 1 нче кушымтада расланган гариза формасы буенча мөрәҗәгать итүче үзенең торак мәйданын алмаштырырга сорый торган торак мәйданны күрсәтергә кирәк. Шул ук вакытта дәгъва белдерелә торган норма гражданның торак урынны алмаштыру варианты булмаганда алмаштыру өчен башка торак урынны сайлау турында гариза бирүгә хокукын күздә тотмый, бу, аның фикеренчә, Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килә.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Г.С. Хәлиуллина Татарстан Республикасы Конституция судыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2008 елның 3 июнендәге 2565 номерлы карары белән расланган Муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру тәртибе турында нигезләмәнең 2.1 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 55 һәм 58 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урыннарны алмаштыру Россия Федерациясе Торак кодексының 72, 73 һәм 74 статьяларында билгеләнгән кагыйдәләр буенча башкарыла. Торак урынны социаль наем шартнамәсе буенча яллаучы яллауга бирүче һәм үзе белән бергә яшәүче, шул исәптән вакытлыча башка җирдә булган гаилә әгъзаларының язма рөхсәте белән алар биләгән торак урынны социаль наем шартнамәсе буенча башка яллаучыга бирелгән торак урынга алмаштырырга хокуклы (72 статьяның 1 өлеше).

Күрсәтелгән хокукый җайга салуда дәүләт яки муниципаль торак фонд милегендә булган һәм гражданга социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урынны алмаштырган вакытта федераль закон чыгаручы андый урын милекчесенең аны алмаштыру вариантларын сайлау бурычын күздә тотмый.

Торак законнары нормаларын гамәлгә ашыру һәм Казан шәһәре муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру процедурасын камилләштерү максатларында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан карала торган тәртип расланган, ул муниципаль торак фондының гражданнар социаль наем шартнамәләре нигезендә биләп торган торак урыннарын алмаштыру кагыйдәләрен билгели.

Гражданнарның торак урынны алмаштыру вариантлары булмаганда җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль милектәге торак урыннарны алмаштыру вариантларын эзләү

җирле үзидарә органнары бурычларына керми, чөнки андый вәкаләт гамәлдәге законнарда каралмаган, ул аларның дискрециясе генә булып тора.

Шулай итеп, Муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру тәртибе турында нигезләмәнең дәгъвалана торган 2.1 пунктында аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк һәм ул кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен боза торган итеп карала алмый. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә гражданка Г.С. Хәлиуллина шикаяте карала алмый. Дәгъвалана торган хокукый җайга салуга мөрәҗәгать итүче фикеренчә максатка ярашлы үзгәрешләр керту исә Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы белән билгеләнгән компетенциясенә керми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

билгеләде:

1. «Казан шәһәре муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру тәртибе турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2008 елның 3 июнендәге 2565 номерлы карары белән расланган Муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру тәртибе турында нигезләмәнең 2.1 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.С. Хәлиуллина шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Г.С. Хәлиуллинага һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 7-О

Татарстан Республикасы Конституция суды

ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

о прекращении производства по жалобе гражданки Г.З. Галимзяновой на нарушение ее конституционных прав и свобод статьей 8 Закона Республики Татарстан от 25 июня 2013 года № 52-ЗРТ «Об организации проведения капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах в Республике Татарстан», абзацем сорок шестым раздела VII Краткосрочного плана реализации Региональной программы капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах, расположенных на территории Республики Татарстан, утвержденной постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 31 декабря 2013 года № 1146, в 2016 году, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 21 марта 2016 года № 152, разделом V Краткосрочного плана реализации на территории города Казани Региональной программы капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах, расположенных на территории Республики Татарстан, утвержденной постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 31 декабря 2013 года № 1146, в 2016—2017 годах, утвержденного постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 20 февраля 2016 года № 675, а также названным постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани в целом

10 мая
2017 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании сообщение судьи А.Р. Шакараева о прекращении производства по жалобе гражданки Г.З. Галимзяновой,

установил:

В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка Г.З. Галимзянова с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод статьей 8 Закона Республики Татарстан от 25 июня 2013 года № 52-ЗРТ «Об организации проведения капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах в Республике Татарстан», абзацем сорок шестым раздела VII Краткосрочного плана реализации Региональной программы капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах, расположенных на территории Республики Татарстан, утвержденной постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 31 декабря 2013 года № 1146, в 2016 году, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 21 марта 2016 года № 152, разделом V Краткосрочного плана реализации на территории города Казани Региональной программы капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах, расположенных на территории Республики Татарстан, утвержденной постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 31 декабря 2013 года № 1146, в 2016—2017 годах,

утвержденного постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 20 февраля 2016 года № 675, а также названным постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани в целом по порядку его официального опубликования.

Однако 20 марта 2017 года гражданка Г.З. Галимзянова обратилась в Конституционный суд Республики Татарстан с заявлением об отзыве своей жалобы.

В соответствии со статьей 47 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» обращение в Конституционный суд Республики Татарстан может быть отозвано заявителем до начала рассмотрения дела в заседании Конституционного суда Республики Татарстан. В случае отзыва обращения производство по делу прекращается.

Поскольку заявительница отозвала свое обращение до начала рассмотрения дела в заседании Конституционного суда Республики Татарстан, производство по данной жалобе подлежит прекращению.

Исходя из изложенного, руководствуясь статьями 47, 63, частями первой и пятой статьи 66, статьей 72 и частью первой статьи 73 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

определил:

1. Производство по жалобе гражданки Г.З. Галимзяновой на нарушение ее конституционных прав и свобод статьей 8 Закона Республики Татарстан от 25 июня 2013 года № 52-ЗРТ «Об организации проведения капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах в Республике Татарстан», абзацем сорок шестым раздела VII Краткосрочного плана реализации Региональной программы капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах, расположенных на территории Республики Татарстан, утвержденной постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 31 декабря 2013 года № 1146, в 2016 году, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 21 марта 2016 года № 152, разделом V Краткосрочного плана реализации на территории города Казани Региональной программы капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах, расположенных на территории Республики Татарстан, утвержденной постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 31 декабря 2013 года № 1146, в 2016—2017 годах, утвержденного постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 20 февраля 2016 года № 675, а также названным постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани в целом прекратить в связи с отзывом заявительницей данной жалобы.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке Г.З. Галимзяновой.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 11-О

Конституционный суд
страция таянырга тиешле критерийлар билгеләми. Шул ук вакытта мөрәҗәгать итүче Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 статьясындагы 1 өлешенең кырык беренче абзацы нигезендә муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибен билгеләү Казан шәһәр Думасы компетенциясенә кертелгән дип күрсәтә. Ул шулай ук билгеләгәнчә, бюджет ассигнованиеләрен бүлү критерийларының булмавы андый бүленеш буенча карарны ирекле кабул итүгә һәм ремонтланырга тиешле юлларны һәм квартал эчендәге машина юлларын бернинди дә объектив факторларга бәйле булмаган сайлауга китерә, бу аның конституциячел хокукларын боза.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Д.В. Кузнецова Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Казан шәһәренең муниципаль юл фонды турында» Казан шәһәр Думасының 2013 елның 29 ноябрендәге 2-27 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибенең 3.3 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче өлеш), 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. «Казан шәһәренең муниципаль юл фонды турында» Казан шәһәр Думасының 2013 елның 29 ноябрендәге 2-27 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибенең мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган 3.3 пункты Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметын тәшкил иткән иде инде. 2017 елның 17 мартындагы 72-П номерлы карарында Татарстан Республикасы Конституция суды Тәртипнең 3.3 пунктында билгеләнгән хокукый җайга салу, юл фонды бюджет ассигнованиеләренең расланган күләмен чыгымнарның максатчан юнәлешләре буенча бүлү критерийларын кертеп, юридик көче аларны бары тик бергә куллану юлы белән генә гамәлгә ашырыла торган бердәм нормалар комплексыннан чыкканга күрә, кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен боза торган итеп карала алмый дигән нәтиҗәгә килә. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды юл фондыннан акчалар бүлеп бирүнең төп критерийлары булып гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларының, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренең, квартал эчендәге машина юлларының техник торышының норматив таләпләргә туры килмәве, шулай ук юл полотносының саклануын һәм торгызылуын тәэмин итүнең объектив кирәклеге тора, дип күрсәтте.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Конституция суды юл фонды бюджет ассигнованиеләрен бүлү һәм ремонтланулары юл фондыннан финансланырга тиешле гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен, квартал эчендәге машина юлларын сайлап алу ирекле түгел, чөнки Казан шәһәре

муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләре күләмен бүлү турында карар кабул иткән вакытта, бүленә торган акчаларның каралган максатларга ярашлы булу принцибын исәпкә алып, бөтен мәсьәләләр комплексын, шул исәптән аларның техник торышын бәяләү белән бәйле булганнарын өйрәнергә тиеш, дип аеруча билгеләде.

Шулай итеп, гражданка Д.В. Кузнецова мөрәҗәгатенең предметы булып аңа карата Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан үз көчен саклый торган карар чыгарылган нигезләмә булганга күрә, мөрәҗәгать итүченең шикаяте «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 3 пункты нигезендә карауга алына алмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 3 пунктына, 66 статьясындагы беренче һәм бишенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72 статьяларына, 73 статьясындагы беренче өлешенә таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

билгеләде:

1. «Казан шәһәренең муниципаль юл фонды турында» Казан шәһәр Думасының 2013 елның 29 ноябрендәге 2-27 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибенең 3.3 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Д.В. Кузнецова шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки элегрәк мөрәҗәгать итү предметы буенча Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан үз көчен саклый торган карар чыгарылган.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Д.В. Кузнецовага һәм Казан шәһәр Думасына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 14-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

15 мая
2017 года
город Казань

об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки З.И. Михайловой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 3.3 Порядка формирования и использования бюджетных ассигнований муниципального дорожного фонда города Казани, утвержденного решением Казанской городской Думы от 29 ноября 2013 года № 2-27 «О муниципальном дорожном фонде города Казани»

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Р.А. Сахиевой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки З.И. Михайловой,

установил:

1.В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка З.И. Михайлова с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 3.3 Порядка формирования и использования бюджетных ассигнований муниципального дорожного фонда города Казани, утвержденного решением Казанской городской Думы от 29 ноября 2013 года № 2-27 «О муниципальном дорожном фонде города Казани» (далее также — Порядок).

Согласно пункту 3.3 Порядка распределение утвержденного объема бюджетных ассигнований муниципального дорожного фонда города Казани по целевым направлениям расходов на очередной финансовый год утверждается Исполнительным комитетом муниципального образования города Казани.

Как следует из жалобы и приложенных к ней копий документов, заявительница проживает в многоквартирном доме, расположенном по адресу город Казань, ул. Академика Лаврентьева. Она отмечает, что асфальтовое покрытие дороги и тротуаров двора в настоящее время находится в очень изношенном состоянии. С просьбой о ремонте асфальтового покрытия дворовой территории, проезжей части и тротуаров гражданка З.И. Михайлова обращалась в администрацию Авиастроительного и Ново-Савиновского районов Исполнительного комитета муниципального образования города Казани, а также в Казанскую городскую Думу. Однако ремонтные работы произведены не были.

По мнению гражданки З.И. Михайловой, пункт 3.3 Порядка, предоставляя Исполнительному комитету муниципального образования города Казани полномочие по распределению бюджетных ассигнований дорожного фонда, не устанавливает критерии, которыми местная администрация должна руководствоваться, осуществляя такое распределение. Вместе с тем заявительница указывает, что согласно абзацу сорок первому части 1 статьи 28 Устава муниципального образования города Казани, утвержденного решением представительного органа муниципального образования города Казани от 17 декабря 2005 года № 3-5, установление

порядка формирования и использования бюджетных ассигнований муниципального дорожного фонда отнесено к компетенции Казанской городской Думы. Она также отмечает, что отсутствие критериев распределения бюджетных ассигнований приводит к произвольному принятию решения по такому распределению и к не обусловленному никакими объективными факторами выбору ремонтируемых дорог и внутриквартальных проездов, что нарушает ее конституционные права.

На основании изложенного гражданка З.И. Михайлова просит Конституционный суд Республики Татарстан признать пункт 3.3 Порядка формирования и использования бюджетных ассигнований муниципального дорожного фонда города Казани, утвержденного решением Казанской городской Думы от 29 ноября 2013 года № 2-27 «О муниципальном дорожном фонде города Казани», не соответствующим статьям 28 (часть первая), 58 (часть вторая) Конституции Республики Татарстан.

2.Оспариваемый заявительницей пункт 3.3 Порядка формирования и использования бюджетных ассигнований муниципального дорожного фонда города Казани, утвержденного решением Казанской городской Думы от 29 ноября 2013 года № 2-27 «О муниципальном дорожном фонде города Казани», уже был предметом рассмотрения Конституционного суда Республики Татарстан. В постановлении от 17 марта 2017 года № 72-П Конституционный суд Республики Татарстан пришел к выводу, что установленное в пункте 3.3 Порядка правовое регулирование не может рассматриваться как нарушающее конституционные права и свободы человека и гражданина, поскольку вытекает из единого комплекса норм, юридическая сила которых реализуется только путем применения их в совокупности, включая критерии распределения утвержденного объема бюджетных ассигнований дорожного фонда по целевым направлениям расходов. При этом Конституционный суд Республики Татарстан указал, что основными критериями, предопределяющими выделение денежных средств из дорожного фонда, являются несоответствие технического состояния автомобильных дорог общего пользования местного значения, дворовых территорий многоквартирных домов, внутриквартальных проездов нормативным требованиям, а также объективная необходимость обеспечения сохранности и восстановления дорожного полотна.

Кроме того, Конституционный суд Республики Татарстан особо отметил, что распределение бюджетных ассигнований дорожного фонда и выбор автомобильных дорог общего пользования местного значения, дворовых территорий многоквартирных домов, внутриквартальных проездов, ремонт которых подлежит финансированию из дорожного фонда, не являются произвольными, поскольку Исполнительный комитет муниципального образования города Казани при принятии решения о распределении объема бюджетных ассигнований муниципального дорожного фонда должен исследовать весь комплекс вопросов, в том числе связанных с оценкой их технического состояния, с учетом принципа соразмерности распределяемых средств преследуемым целям.

Таким образом, поскольку предметом обращения гражданки

З.И. Михайловой является положение, относительно которого Конституционным судом Республики Татарстан уже вынесено постановление, сохраняющее свою силу, жалоба заявительницы на основании пункта 3 части первой статьи 46 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не может быть принята к рассмотрению.

На основании изложенного и руководствуясь пунктом 3 части первой статьи 46, частями первой и пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, частью первой статьи 73 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

определил:

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки З.И. Михайловой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 3.3 Порядка формирования и использования бюджетных ассигнований муниципального дорожного фонда города Казани, утвержденного решением Казанской городской Думы от 29 ноября 2013 года № 2-27 «О муниципальном дорожном фонде города Казани», поскольку по предмету обращения Конституционным судом Республики Татарстан ранее было вынесено постановление, сохраняющее свою силу.

2.Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3.Копию настоящего Определения направить гражданке З.И. Михайловой и в Казанскую городскую Думу.

4.Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 15-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ

«Казан шәһәренең муниципаль юл фонды турында» Казан шәһәр Думасының 2013 елның 29 ноябрендәге 2-27 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибенең 3.3 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка З.И. Михайлова шикаятен карауга алудан баш тарту турында

2017 ел
15 май
Казан шәһәре

БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка З.И. Михайлова шикаятен алдан өйрәнгән судья Р.Г. Сәхиева бәяләмәсен тыңлаганнан соң

а ч ы к л а д ы :

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка З.И. Михайлова «Казан шәһәренең муниципаль юл фонды турында» Казан шәһәр Думасының 2013 елның 29 ноябрендәге 2-27 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибенең (алга таба шулай ук — Тәртип) 3.3 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Тәртипнең 3.3 пункты нигезендә чыгымнарның максатчан билгеләнеше буенча Казан шәһәренең муниципаль юл фондының расланган бюджет ассигнованиеләре күләме бүленеше алдагы финанс елына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче Казан шәһәре, Академик Лаврентьев урамы адресы буенча урнашкан күпфатирлы йортта яши. Ул ишегалдындагы юлның һәм тротуарларның асфальт түшәмәсе хәзерге вакытта бик нык таушалган хәлдә дип билгели. Ишегалды территориясе, машина үтә торган юл өлеше һәм тротуарларның асфальт түшәмәсен ремонтлауны сорап, гражданка З.И. Михайлова Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясенә, шулай ук Казан шәһәр Думасына мөрәҗәгать иткән. Ләкин ремонт эшләре башкарылмаган.

Гражданка З.И. Михайлова фикеренчә, Тәртипнең 3.3 пункты, юл фондының бюджет ассигнованиеләрен бүлү вәкаләтен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына тапшырып, андый бүленешне башкарганда җирле админи-

страция таянырга тиешле критерийлар билгеләми. Шул ук вакытта мөрәҗәгать итүче Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 статьясындагы 1 өлешенең кырык беренче абзацы нигезендә муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибен билгеләү Казан шәһәр Думасы компетенциясенә кертелгән дип күрсәтә. Ул шулай ук билгеләгәнчә, бюджет ассигнованиеләрен бүлү критерийларының булмавы андый бүленеш буенча карарны ирекле кабул итүгә һәм ремонтланырга тиешле юлларны һәм квартал эчендәге машина юлларын бернинди дә объектив факторларга бәйле булмаган сайлауга китерә, бу аның конституциячел хокукларын боза.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка З.И. Михайлова Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Казан шәһәренең муниципаль юл фонды турында» Казан шәһәр Думасының 2013 елның 29 ноябрендәге

2-27 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибенең 3.3 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче өлеш), 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. «Казан шәһәренең муниципаль юл фонды турында» Казан шәһәр Думасының 2013 елның 29 ноябрендәге 2-27 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибенең мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган 3.3 пункты Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметын тәшкил иткән иде инде. 2017 елның 17 мартындагы 72-П номерлы карарында Татарстан Республикасы Конституция суды Тәртипнең 3.3 пунктында билгеләнгән хокукый җайга салу, юл фонды бюджет ассигнованиеләренең расланган күләмен чыгымнарның максатчан юнәлешләре буенча бүлү критерийларын кертеп, юридик көче аларны бары тик бергә куллану юлы белән генә гамәлгә ашырыла торган бердәм нормалар комплексыннан чыкканга күрә, кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен боза торган итеп карала алмый дигән нәтиҗәгә килә. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды юл фондыннан акчалар бүлеп бирүнең төп критерийлары булып гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларының, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренең, квартал эчендәге машина юлларының техник торышының норматив таләпләргә туры килмәве, шулай ук юл полотносының саклануын һәм торгызылуын тәэмин итүнең объектив кирәклеге тора, дип күрсәтте.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Конституция суды юл фонды бюджет ассигнованиеләрен бүлү һәм ремонтланулары юл фондыннан финансланырга тиешле гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен, квартал эчендәге ма-

шина юлларын сайлап алу ирекле түгел, чөнки Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләре күләмен бүлү турында карар кабул иткән вакытта, бүленә торган акчаларның каралган максатларга ярашлы булу принцибын исәпкә алып, бөтен мәсьәләләр комплексын, шул исәптән аларның техник торышын бәяләү белән бәйле булганнарын өйрәнергә тиеш, дип аеруча билгеләде.

Шулай итеп, гражданка З.И. Михайлова мөрәҗәгатенең предметы булып аңа карата Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан үз көчен саклый торган карар чыгарылган нигезләмә булганга күрә, мөрәҗәгать итүченең шикаяте «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 3 пункты нигезендә карауга алына алмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 3 пунктына, 66 статьясындагы беренче һәм бишенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72 статьяларына, 73 статьясындагы беренче өлешенә таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

билгеләде:

1. «Казан шәһәренең муниципаль юл фонды турында» Казан шәһәр Думасының 2013 елның 29 ноябрендәге 2-27 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибенең 3.3 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка З.И. Михайлова шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки элегрәк мөрәҗәгать итү предметы буенча Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан үз көчен саклый торган карар чыгарылган.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка З.И. Михайловага һәм Казан шәһәр Думасына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 15-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

15 мая 2017 года
город Казань

об отказе в принятии к рассмотрению ходатайства гражданки Р.Х. Кашаповой об официальном разъяснении определения Конституционного суда Республики Татарстан от 6 июня 2016 года № 11-О

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Л.В. Кузьминой, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи А.Р. Шакараева, проводившего на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение обращения гражданки Р.Х. Кашаповой,

установил:

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка Р.Х. Кашапова с ходатайством о разъяснении определения Конституционного суда Республики Татарстан от 6 июня 2016 года № 11-О, которым заявительнице было отказано в принятии к рассмотрению жалобы на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 2 приложения № 1 и пунктом 2 приложения № 2 к постановлению Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 23 декабря 2015 года № 4459 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани на 2016 год».

Оспариваемыми нормами была установлена плата за управление многоквартирным домом в размере 2 руб. 70 коп. с 1 кв. метра общей площади жилого помещения в месяц на 1 и 2 полугодия 2016 года. В данную стоимость, по мнению гражданки Р.Х. Кашаповой, была включена плата за услуги общества с ограниченной ответственностью «Единый расчетный центр г. Казани» (далее — ООО «ЕРЦ г. Казани»), размер которой для их многоквартирного дома составляет 1 руб. 23 коп. с 1 кв. метра общей площади жилого помещения в месяц.

Конституционный суд Республики Татарстан в определении от 6 июня 2016 года № 11-О пришел к выводу, что обжалуемые заявительницей нормативные положения не содержат неопределенности в вопросе их соответствия Конституции Республики Татарстан.

В ходатайстве о разъяснении данного определения Конституционного суда Республики Татарстан гражданка Р.Х. Кашапова указывает, что в своей жалобе в Конституционный суд Республики Татарстан она оспаривала конституционность вышеназванных норм, поскольку ими в тариф за управление многоквартирным домом включалась оплата услуг за осуществление расчетов ООО «ЕРЦ г. Казани», не являющимся платежным агентом в соответствии с Федеральным законом от 3 июня 2009 года № 103-ФЗ «О деятельности по приему платежей физических лиц, осуществляемой платежными агентами».

По ее мнению, наличие у граждан в соответствии с Жилищным кодексом Российской Федерации права самим устанавливать тарифы на общем собрании не означает, что органы местного самоуправления вправе включать в тариф за управление многоквартирным домом любые затраты и принимать не соответствующие Конституции Республики Татарстан нормативные правовые акты. В обоснование своей позиции заявительница ссылается на письмо Управления Федеральной антимонопольной службы по Республике Татарстан от 28 сентября 2016 года № ИП-05/13827, из содержания которого, в частности, следует, что в действиях УК «Жилищник-4» выявлены признаки нарушения пункта 3 части 1 статьи 10 Федерального закона от 26 июля 2006 года № 135-ФЗ «О защите конкуренции», выразившегося в навязывании собственникам помещений в многоквартирных домах условия о внесении платы за жилое помещение и коммунальные услуги на расчетный счет ООО «ЕРЦ г. Казани», которое не является исполнителем коммунальных услуг и платежным агентом в соответствии с Федеральным законом от 3 июня 2009 года № 103-ФЗ «О деятельности по приему платежей физических лиц, осуществляемой платежными агентами».

На основании изложенного, руководствуясь статьей 77 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», гражданка Р.Х. Кашапова просит Конституционный суд Республики Татарстан разъяснить определение Конституционного суда Республики Татарстан от 6 июня 2016 года № 11-О в части того, признаны ли оспоренные нормы не содержащими неопределенности в вопросе об их соответствии Конституции Республики Татарстан в том числе постольку, поскольку в установленный ими тариф за управление многоквартирным домом не может входить оплата услуг за осуществление расчетов организацией, не являющейся исполнителем коммунальных услуг и платежным агентом.

2. В соответствии со статьей 77 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» официальное разъяснение решения Конституционного суда Республики Татарстан дается только самим Конституционным судом Республики Татарстан в своем заседании, в частности, по ходатайству лица, имеющего право на обращение в Конституционный суд Республики Татарстан. Как уже отмечал Конституционный суд Республики Татарстан, по смыслу данной нормы в ее взаимосвязи со статьей 68 указанного Закона официальное разъяснение не может быть простым воспроизведением решения суда и не должно выходить за пределы произведенной Конституционным судом Республики Татарстан проверки конституционности соответствующего нормативного правового акта (определения от 4 октября 2001 года № 5-О и от 14 декабря 2005 года № 11-О).

Конституционный Суд Российской Федерации также указывал, что ходатайство о даче официального разъяснения не может быть рассмотрено, если представленные в нем вопросы не требуют какого-либо дополнительного истолкования решения по существу или формулирования новых правовых позиций (определения от 20

апреля 2010 года № 593-О-Р, от 24 сентября 2013 года № 1270-О-Р, от 24 декабря 2013 года № 1928-О-Р).

Из содержания мотивировочной части определения Конституционного суда Республики Татарстан от 6 июня 2016 года № 11-О следует, что обжалуемое заявительницей правовое регулирование принято Исполнительным комитетом муниципального образования города Казани в рамках реализации норм жилищного законодательства и, исходя из своей правовой природы, распространяется на собственников помещений в многоквартирных домах, которые не воспользовались своим правом на самостоятельное принятие решения о выборе способа управления многоквартирным домом и (или) об установлении размера платы за содержание жилых помещений по видам услуг. Обжалуемые нормы сами по себе не предусматривают ограничений в реализации собственниками помещений в многоквартирных домах права по принятию на общем собрании собственников решения об установлении размера платы за содержание жилого помещения, условиях и порядке ее внесения. При этом Конституционный суд Республики Татарстан также отметил, что, исходя из содержания пункта 64 Правил предоставления коммунальных услуг собственникам и пользователям помещений в многоквартирных домах и жилых домов, утвержденных постановлением Правительства Российской Федерации от 6 мая 2011 года № 354 «О предоставлении коммунальных услуг собственникам и пользователям помещений в многоквартирных домах и жилых домов», собственники жилых помещений в многоквартирном доме при наличии договора о предоставлении коммунальных услуг, заключенного с управляющей организацией, вправе вносить плату за такие услуги в том числе через платежных агентов или банковских платежных агентов, указанных ресурсоснабжающей организацией.

Рассматривая оспариваемые нормы, Конституционный суд Республики Татарстан давал им оценку исходя из их места в системе действующего правового регулирования и правового смысла, предусматривающего, что в тариф за управление многоквартирным домом может входить оплата услуг за осуществление расчетов только организацией, реализующей свою деятельность в соответствии с Федеральным законом от 3 июня 2009 года № 103-Федерального закона «О деятельности по приему платежей физических лиц, осуществляемой платежными агентами», положениями которого закреплены правовые основы регулирования отношений, возникающих при осуществлении деятельности по приему платежным агентом от плательщика денежных средств, направленных на исполнение денежных обязательств физического лица перед поставщиком по оплате товаров (работ, услуг).

Следовательно, содержание и смысл определения Конституционного суда Республики Татарстан от 6 июня 2016 года № 11-О выражены исчерпывающим образом, полностью основаны на нормах действующего законодательства Российской Федерации и Конституции Республики Татарстан и какая-либо правовая неопределенность по ним отсутствует. Вследствие этого указанное определение Конституционного суда Республики Татарстан не требует дополнительной детализации или уточнения.

Из ходатайства гражданки Р.Х. Кашаповой следует, что ее обращение в Конституционный суд Республики Татарстан обусловлено, по сути, не отсутствием определенности или ясности в правовой позиции, сформулированной в определении от 6 июня 2016 года № 11-О, а интерпретацией оспариваемых норм в правоприменительной практике. Между тем вопросы о том, является ли ООО «ЕРЦ г. Казани» надлежащим платежным агентом, обоснованно ли установлены размеры тарифов, применяемых при расчете платы за содержание жилых помещений, специально Конституционным судом Республики Татарстан не исследовались, поскольку в силу части девятой статьи 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» Конституционный суд Республики Татарстан решает исключительно вопросы права и при осуществлении конституционного судопроизводства воздерживается от установления и исследования фактических обстоятельств во всех случаях, когда это входит в компетенцию других судов или иных органов государственной власти Республики Татарстан.

На основании изложенного, руководствуясь статьей 6, пунктом 3 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, частями первой, второй и шестой статьи 68, статьями 69, 72, 73 и 77 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

определил:

1. Отказать в принятии к рассмотрению ходатайства гражданки Р.Х. Кашаповой об официальном разъяснении определения Конституционного суда Республики Татарстан от 6 июня 2016 года № 11-О, поскольку для разрешения поставленных заявительницей вопросов официальное разъяснение данного определения не требуется.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данному обращению окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке Р.Х. Кашаповой и в Исполнительный комитет муниципального образования города Казани.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 16-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ

Татарстан Республикасы Конституция судының 2016 елның 6 июнендәге 11-О номерлы билгеләмәсен рәсми аңлату турында гражданка Р.Х. Кашапова үтенечнамәсен карауга алудан баш тарту хакында

2017 ел
15 май
Казан шәһәре

БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Р.Х. Кашапова мөрәҗәгатен алдан өйрәнгән судья А.Р. Шакараев бәяләмәсен тыңлаганнан соң

а ч ы к л а д ы :

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Р.Х. Кашапова Татарстан Республикасы Конституция судының 2016 елның 6 июнендәге 11-О номерлы билгеләмәсен аңлату турында үтенечнамә белән мөрәҗәгать итте, аның белән мөрәҗәгать итүчегә «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы карарына 1 нче кушымтаның 2 пункты һәм 2 нче кушымтаның 2 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаятен карауга алудан баш тартылган.

Дәгъвалана торган нормалар белән 2016 елның 1 һәм 2 яртыеллыкларына күпфатирлы йорт белән идарә итү өчен түләү айга торак урынның гомуми мәйданының 1 кв. метрыннан 2 сум 70 тиен күләмендә билгеләнгән. Әлеге бәягә, гражданка Р.Х. Кашапова фикеренчә, «Казан шәһәренең бердәм исәп-хисап үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба — «Казан шәһәренең БИХҮ» ҖЧҖ) хезмәтләре өчен түләү кергән, аның күләме аларның күпфатирлы йортлары өчен айга торак урынның гомуми мәйданының 1 кв. метрыннан 1 сум 23 тиен тәшкил итә.

Татарстан Республикасы Конституция суды 2016 елның 6 июнендәге 11-О номерлы билгеләмәсендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган норматив нигезләмәләрдә аларның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк дигән нәтиҗәгә килде.

Татарстан Республикасы Конституция судының әлеге билгеләмәсен аңлату турындагы үтенечнамәдә гражданка Р.Х. Кашапова шуны күрсәтә: Татарстан Республикасы Конституция судына шикаятендә ул югарыда аталган нормаларның конституциячеллегенә алар күпфатирлы йорт белән идарә итү тари-

фына «Физик затларның түләү агентлары гамәлгә ашыра торган түләүләрен кабул итү эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 июнендәге 103-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә түләү агенты булмаган «Казан шәһәренең БИХҮ» ҖЧҖ тарафыннан исәп-хисаплар башкару хезмәтләре өчен түләүне керткәнгә күрә дәгъва белдергән.

Аның фикеренчә, Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә гражданнарның гомуми җыелышта тарифларны үзләре билгеләү хокукы булу җирле үзидарә органнары күпфатирлы йорт белән идарә итү тарифына теләсә нинди чыгымнар кертергә һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми торган норматив хокукый актлар кабул итәргә хокуклы дигәнне аңлатмый. Үз позициясен нигезләп, мөрәҗәгать итүче Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 2016 елның 28 сентябрендәге ИП-05/13827 номерлы хатын күрсәтә, аның эчтәлегеннән, аерым алганда, «Жилищник-4» ИК эшчәнлегендә «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктын бозу билгеләре ачыкланганлыгы аңлашыла, әлеге бозу күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләрен торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүне «Физик затларның түләү агентлары гамәлгә ашыра торган түләүләрен кабул итү эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 июнендәге 103-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә түләү агенты булмаган «Казан шәһәренең БИХҮ» ҖЧҖның исәп-хисап счетына кертергә мәҗбүр итүдә чагыла.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 77 статьясына таянып, гражданка Р.Х. Кашапова Татарстан Республикасы Конституция судыннан Татарстан Республикасы Конституция судының 2016 елның 6 июнендәге 11-О номерлы билгеләмәсен дәгъвалана торган нормаларда шул исәптән алар билгеләгән күпфатирлы йорт белән идарә итү тарифына коммуналь хезмәтләрне үтәүче һәм түләү агенты булмаган оешма тарафыннан исәп-хисаплар башкару хезмәтләре өчен түләү керә алмаганга күрә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәү мәсьәләсендә билгесезлек юк дип танылу өлешендә аңлатуны сорый.

2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 77 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды карарына рәсми аңлатма, аерым алганда, Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итү хокукына ия затның үтенечнамәсе буенча бары тик Татарстан Республикасы Конституция судының үзе тарафыннан үз утырышында гына бирелә. Татарстан Республикасы Конституция суды билгеләп үткәнчә, рәсми аңлатма, күрсәтелгән Законның 68 статьясы белән үзара бәйләнештә әлеге норманың мәгънәсе буенча, суд карарын гади кабатлау гына була алмый һәм тиешле норматив хокукый актның конституциячеллеген Татарстан Республикасы Конституция суды башкарган тикшерү чикләреннән чыкмаска тиеш (2001 елның 4 октябрендәге 5-О номерлы һәм 2005 елның 14 декабрендәге 11-О номерлы билгеләмәләр).

Россия Федерациясе Конституция Суды рәсми аңлатма бирү турындагы үтенечнамә, әгәр анда бирелгән сораулар карарны асылда ничек тә булса өстәмә аңлатуны яисә яңа хокукый позицияләр формалаштыруны таләп итмәсә, карала алмый дип шулай ук күрсәткән иде (2010 елның 20 апрелендәге 593-О-Р номерлы, 2013 елның 24 сентябрендәге 1270-О-Р номерлы, 2013 елның 24 декабрендәге 1928-О-Р номерлы билгеләмәләр).

Татарстан Республикасы Конституция судының 2016 елның 6 июнендәге 11-О номерлы билгеләмәсенең дәлилләү өлеше эчтәлегеннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче дәгъва белдерә торган хокукый җайга салу Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан торак законнары нормаларын гамәлгә ашыру кысаларында кабул ителгән һәм, үзенең хокукый табигатеннән чыгып, күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) торак урыннарны карап тоткан өчен хезмәт күрсәтү төрләре буенча түләү күләмен билгеләү хакында мөстәкыйль карар кабул итүгә хокукларыннан файдаланмаган күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренә кагыла. Дәгъва белдерелә торган нормалар үзеннән-үзе күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләре тарафыннан үзләренең гомуми җыелышында торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү, аны кертү шартлары һәм тәртибе турында карар кабул итү хокукын гамәлгә ашыруда чикләүләр күздә тотмыйлар. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды шулай ук «Күпфатирлы йортлар һәм торак йортлардагы урыннар милекчеләренә һәм кулланучыларына коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортлар һәм торак йортлардагы урыннар милекчеләренә һәм кулланучыларына коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләренең 64 пункты эчтәлегеннән чыгып, күпфатирлы йорттагы торак урыннар милекчеләре, коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында идарәче оешма белән төзелгән шартнамә булганда, андый хезмәтләр өчен түләүне шул исәптән ресурслар белән тәэмин итүче оешма күрсәткән түләү агентлары яки банк түләү агентлары аша кертергә хокуклы, дип билгеләде.

Дәгъвалана торган нормаларны караганда, Татарстан Республикасы Конституция суды аларны гамәлдәге хокукый җайга салу системасындагы урыннарыннан һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү тарифына нигезләмәләре белән физик затның тәэмин итүче алдындагы товарлар (эшләр, хезмәтләр) өчен түләү буенча акчалата бурычларын үтәүгә юнәлгән акчаларны түләү агенты тарафыннан түләүчедән кабул итү эшчәнлеген башкарганда барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга салуның хокукый нигезләре беркетелгән «Физик затларның түләү агентлары гамәлгә ашыра торган түләүләрен кабул итү эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 июнендәге 103-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешма тарафыннан гына исәпхисапларны башкару хезмәтләре өчен түләү керә алганлыгын күздә тота торган хокукый мәгънәсеннән чыгып бәяләгән.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Конституция судының 2016 елның 6 июнендәге 11-О номерлы билгеләмәсенең эчтәлеге һәм мәгънәсе җитәрлек дәрәҗәдә ачык чагылдырылган, Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары һәм Татарстан Республикасы Конституциясе нормаларына тулысынча таяна һәм алар буенча нинди дә булса хокукый билгесезлек юк. Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция судының күрәтелгән билгеләмәсе өстәмә тәфсилләүне яисә аныклауны таләп итми.

Гражданка Р.Х. Кашапова үтенечнамәсеннән аңлашылганча, аның Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгате, асылда, 2016 елның 6 июнендәге 11-О номерлы билгеләмәдә булдырылган хокукый позициядә билгелелек яки ачыклык булу-булмауга түгел, ә хокук куллану практикасында дәгъвалана торган нормаларны интерпретацияләүгә бәйле. Шул ук вакытта «Казан шәһәренең БИХҮ» ҖЧҖ тиешле түләү агенты булып торамы-юкмы, торак урыннарны карап тоткан өчен түләүне хисаплаганда кулланыла торган тарифларның нигезле билгеләнгән булу-булмавы турындагы мәсьәләләр Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан махсус тикшерелмәде, чөнки «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы тугызынчы өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен башкарганда башка судлар яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән органнары компетенциясенә кергән барлык очракларда факттагы хәлләрне ачыклаудан һәм тикшерүдән тыелып кала.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 3 пунктына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 68 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 77 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

билгеләде:

1. Татарстан Республикасы Конституция судының 2016 елның 6 июнендәге 11-О номерлы билгеләмәсен рәсми аңлату турында гражданка Р.Х. Кашапова үтенечнамәсен карауга алудан баш тартырга, чөнки мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләләрне хәл итү өчен әлеге билгеләмәне рәсми аңлату таләп ителми.

2. Бу мөрәҗәгать буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Р.Х. Кашапова-га һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 16-О

Татарстан Республикасы Конституция суды